СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦПИАЛЬ РАЙОНЫ
УРНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты,
Урнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**от «28» октябрь 2021ел** **№29**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карары проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советының 22 октябрь 2018 ел, №28 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән проект буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәкавыл җирлеге Советы карары

проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә;

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибен 3 нче кушымта нигезендә.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2021 елның 30 ноябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Үрнәк авылы, Урман урам, 44 А йорт адресы буенча хакимият бинасында уздырырга.

4. Башкарма комитетка Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегендә яшәүчеләрдән кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

5. Әлеге карарны 2021 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo ktatarstan), Интернет-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru), Үрнәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы — СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ — В.Р.Габделхаков

**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Үрнәк авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Үрнәкавыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 03 декабрендә чыккан 88 номерлы "Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.RU), Арча муниципаль районы сайтында ("Җирлекләр" бүлегендә) бастырып чыгарырга һәм мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге Советының
28.10.2021ел, №29
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре**
**Гомуми нигезләмәләр**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында, әйләнә-тирә мохитне саклау, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.
2.Әлеге Кагыйдәләр оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә барлык физик һәм юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

3.Әлеге Кагыйдәләр җирлек территориясендә гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге таләпләрне билгели:

1) биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен тышкы кыяфәтен тиешенчә карап тоту;

2)төзекләндерү эшләре исемлеге һәм эшләрне башкару ешлыгы;

3) биналарны ( алардагы бүлмәләрне) һәм корылмаларны төзекләндерүдә милекчеләренең катнашу тәртибе;

4)җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту).

4.Территорияләрне төзекләндерү элементларын проектлау һәм урнаштыру билгеләнгән тәртиптә расланган проект документлары нигезендә шәһәр төзелеше һәм җир законнары, махсус нормалар һәм кагыйдәләр, дәүләт стандартлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гамәлгә ашырыла.

**Төп төшенчәләр**

5. Әлеге Кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

**җирле әһәмияттәге автомобиль юлы**-транспорт чаралары хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә һәм аларда урнашкан җир кишәрлекләрен яисә конструктив элементлар (юл полотносы, юл өслеге һ.б.) һәм аның технологик өлеше булган юл корылмалары, саклагыч юл корылмалары, ясалма юл корылмалары, җитештерү объектлары,

автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын үз эченә алган транспорт инфраструктурасы объекты;

**арборицидлар**-чүп үләннәренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;

**фасадның архитектура үзенчәлекләре** - бина фасадның, әйләнә-тирә мохитнең конструктив һәм эстетик сыйфатларын чагылдыручы аерым характеристикалары (стиль һәм композиция бөтенлеге, ритм, үлчәм һәм пропорциональлек, визуаль кабул итү, ачык һәм ябык киңлекләр балансын чагылдыручы үзенчәлекле характеристикалар);

**фонсыз конструкцияләр**- конструкция аерым хәрефләрдән, билгеләмәләрдән, билгеләрдән, декоратив элементлардан торган тышкы мәгълүмат чараларын эшләү ысулы;

**хуҗасыз транспорт чарасы**-милекчесе билгесез яки, законнар белән башкасы каралмаган булса, милекчесе аннан баш тарткан очракта, милекчесе булмаган транспорт чарасы;

**территорияне төзекләндерү** - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру эшчәнлеге, гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга юнәлдерелгән, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, якын-тирә территорияне карап тотуга юнәлтелгән эшчәнлек;

**Сосновский балтырганы** - зур булып үсүчән үсемлек, балтырганнар семьялыгы, зонтиклылар төренә керә. Үсемлек озак төзәлми торган көчле җәрәхәт ясау үзлегенә ия;

**ташлап калдырылган транспорт чарасы** –ишекләре булмау яки ябылмау, тәрәзәләре булмау һ.б аркасында чит затларның керү мөмкинлеге булган, көпчәкләре яраксызга әйләнгән, башка конструктив детальләре яки башкалары булмаган, гомуми файдалану урыннарында (йорт яны территорияләрендә) территорияне җыештыру, махсус транспорт һәм чүп җыю машиналарына подъездларга һәм чүп контейнерларына бару юлында комачаулык тудыра торган, милекче тарафыннан алты ай һәм аннан да күбрәк вакытка калдырылган транспорт чарасы;

**бункер** -зур габаритлы калдыкларны туплау өчен билгеләнгән чүп җыю урыны;

**вертикаль яшелләндерү**- стационар һәм мобиль яшел үсентеләр урнаштыру өчен балкон, лоджия, галерея, терәк стеналар, биналарның һәм корылмаларның алгы өслекләрен куллану;

**витрина**-фасадның бер өлешен алып торучы тоташ пыяла рәвешендә пыяла уем (тәрәзә, витраж);

**барлыкка килгән төзелешнең тышкы архитектурасы**- биналарның һәм аларның фасадларының җирлекнең тышкы кыяфәтен формалаштыручы архитектура-сәнгать һәм шәһәр төзелеше үзенчәлекләре;

**тышкы яктырту ысулы**- мәгълүмати конструкцияне аңа җибәрелгән яктылык чыганагы белән яктыртыла торган яктырту ысулы;

**квартал эчендәге (җирле) юл**-магистраль урамнардан торак йортлар төркемнәренә һәм кварталның башка урыннарына транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән автомобиль юлы;

**төзекләндерүне торгызу**-юлның бөтен киңлегенә ясалма капламны, тротуарны сыйфатлы торгызуны, бордюр ташын кире урнаштыруны, туфракның уңдырышлы катламын торгызуны, газон үләннәрен һәм бозылган яшел үсентеләр утыртуны, реклама конструкцияләрен һәм төзекләндерүнең башка элементларын торгызуны үз эченә алган эшләр комплексы;

**газон** – махсус сайланган үләннәрдән торган, парк һәм ландшафт композициясенә фон яисә мөстәкыйль элемент булып торучы үлән катламы;

**гербицидлар**-үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;

**кунаклар өчен машина туктап тору урыны (стоянка)**-торак зоналарга килүчеләргә җиңел автомобильләр кую өчен билгеләнгән ачык мәйданчык;

**балалар мәйданчыгы**- балалар уеннары өчен билгеләнгән объектлар (таулар, карусельләр, таган, комлыклар һәм (яки) башка шундый объектлар урнашкан җир кишәрлеге);

**ишегалды территориясе**-бер яки берничә күпфатирлы йорт янындагы һәм анда яшәүче затларның һәм җәмәгать биналарының гомуми кулланыштагы һәм аларның эшләвен тәэмин итүче территория. Күпфатирлы йортларның ишегалды территориясендә балалар мәйданчыклары, ял итү урыннары, кер элү урыннары, автомобильләр парковкалары, яшел зоналар һәм башка иҗтимагый файдаланудагы объектлар урнаштырыла;

**ишегалды корылмалары**-җир кишәрлегендә вакытлыча урнашкан ярдәмче корылмалар (кар базлары, күгәрчен оялары, сарайлар);

**мәгълүмат тапшыруның динамик ысулы**- мәгълүматны мәгълүмат алмаштыруны күздә тота торган электрон мәгълүмат туплагычлар һәм табло ярдәмендә тапшыру ысулы;

**йорт биләмәсе**-ишегалды корылмалары булган шәхси торак йорт һәм әлеге йорт урнашкан җир кишәрлеге;

**йорт билгеләре** - аншлаг (урам, мәйдан, проспект исеме күрсәткече), йорт номеры (йорт һәм корпус номеры күрсәткече), подъезд һәм фатирлар номеры күрсәткече, объектның инвалидлар өчен булуы символы, флаглар, истәлекле такталар, полигонометрик билге, янгын гидранты күрсәткече, грунт геодезик

билгеләре күрсәткече, магистраль камералары һәм сүүткәргеч челтәр кое күрсәткечләре, канализация күрсәткече, җир асты газүткәргеч корылмалары күрсәткече);

**сыек көнкүреш калдыклары**-халыкның тормыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә торган хуҗалык-көнкүреш сулары, үзәкләштерелгән су бүлү системасына тоташтырылмаган (технологик яктан тоташтырылмаган) корылмаларга һәм ташландык суларны кабул итү һәм туплау өчен билгеләнгән җайланмалар;

**бина**-капиталь төзелеш объекты, ул автоном рәвештә төзелергә, төзекләндерелергә һәм кулланылырга мөмкин булган бердәм күләмле төзелеш системасын тәшкил итә (төзелешкә бер рөхсәт нигезендә төзелгән);

**яшел утыртмалар**-билгеле бер территориядә агач-куак һәм үләннәр үскән урын;

**җир кишәрлеге** - чикләре федераль законнар нигезендә билгеләнгән җир өслегенең бер өлеше;

**җир эшләре**-җир казу, грунт җәю, территорияне яки грунт катламын бозып, юлларны һәм тротуарлар төзү (җәю) белән бәйле эшләр;

**эшчәнлек алып бару зонасы**- төзелеш, инженерлык коммуникацияләрен урнаштыру, капиталь һәм башка ремонт эшләре рөхсәт ителгән киртәле территория. Башка эш (авария хәлендәгеләрдән тыш) башкару, җиһазлар, материаллар, калдыклар, техник инвентарьлар урнаштыру тыела;

**инженерлык коммуникацияләре**-инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре: сүүткәргеч, канализация, җылылык, торба үткәргечләр, электр тапшыру линияләре, элемтә һәм башка инженерлык корылмалары, җирлек территориясендә булганнары яисә сузыла торган башка инженерлык корылмалары;

**җирлекнең тарихи территорияләре**-XI гасыр башыннан 1959 елга кадәрге чорда үзләштерелгән махсус авыл җирлеге территорияләре, аларга карата тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларының урнаштыруга рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән төрләре һәм типлары, шул исәптән мондый конструкцияләргә карата таләпләр Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), аларны саклау һәм куллану турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән. Җирлекнең тарихи территорияләренең гомуми чикләре Башкарма комитетның муниципаль хокукый актлары белән раслана;

**контейнер** -каты коммуналь калдыклар (зур габаритлы калдыклардан тыш) салу өчен билгеләнгән чүп җыйгыч;

**контейнер мәйданчыгы**-каты коммуналь калдыкларны җыю урыны ( мәйданчыгы), әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү

өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән һәм контейнерлар һәм бункерлар урнаштыру өчен билгеләнгән урын;

**компенсацияле яшелләндерү**-юкка чыгарылган яки зыян күргән агачлар урынына яшел үсентеләрне яңадан утырту;

**түбә яшелләндерүе-** бина һәм корылмаларның түбәләрен архитектура-ландшафт объектлары (газоннар, чәчәк түтәлләре, бакчалары, агачлар һәм куаклар белән мәйданчыклар һәм башкалар) төзү өчен куллану;

**яңгыр канализациясе** - өске (яңгыр, кар), су сибү һәм дренаж суларын җибәрү өчен билгеләнгән инженерлык корылмалары (желоблар, яңгыр кирәк-яраклары, лотоклар һәм торбалар) белән бәйле технологик комплекс;

**кече архитектура формалары** – (алга таба –КАФ) - монументаль-декоратив бизәү элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү җайланмалары (беседкалар, аркалар, бакча-парк скульптурасы, вазоннар, чәчәк түтәлләре, шпалерлар), су җайланмалары (фонтаннар, бюветлар, декоратив сулыклар), муниципаль мебель (ял итү өчен эскәмияләр, җәмәгать урыннары, рекреацияләр һәм ишегаллары территорияләрендә урнаштырылган эскәмияләр, өстәл уеннары өчен өстәлләр, бакча һәм урам җиһазлары), коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар (көнкүреш чүп-чары җыю өчен контейнерлар, урналар, почта тартмалары, инженерлык җиһазлары элементлары) һ.б.;

**җемелдәвек ут** - ут характеристикаларын (төс, яктылык, кабыну чиратлы һ. б.) алмаштыруны күздә тоткан яктылык динамикалы эффект бирә торган ут;

**чүп-чар өеме**-контейнер мәйданчыгында яки теләсә кайсы башка территориядә үзбелдекле ташлану нәтиҗәсендә барлыкка килгән 1 куб. метрдан артмаган күләмдә каты көнкүреш калдыклары һәм зур габаритлы җыелган чүп-чар;

**тышкы яктырту объектлары (яктырту җиһазлары**) - урамнарда, скверларда, паркларда урнаштырылган яктырту приборлары (яктырткычлар, прожекторлар), мондый яктырту өчен махсус билгеләнгән баганаларда, биналарның стеналарында, корылмаларның түшәмнәрендә, металл, тимер-бетон һәм башка биналарның конструкцияләрендә, корылмаларында һәм җәмәгать кулланылышының башка урыннарында урнаштырыла ала;

**барлыкка килгән төзелешнең тышкы архитектура кыяфәтен бозу**-тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларының урнаштыруга рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән төре һәм тибы таләпләрен, шул исәптән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән, җирлекнең барлыкка килгән төзелешенең тышкы архитектура йөзен саклау кирәклеген исәпкә алып, мондый конструкцияләрнең тышкы кыяфәтенә яки урнашу урынына карата таләпләрне үтәмәү;

**рөхсәтсез ясалган чүплек**- 50 кв. метрдан артык мәйданда һәм 30 куб. метрдан артык күләмдә рөхсәтсез каты көнкүреш калдыклары, эре габаритлы яисә төзелеш калдыклары, юридик яки физик затлар эшчәнлеге барышында барлыкка килгән башка чүп-чар ташланган урын;

**стационар булмаган сәүдә объекты**- җир кишәрлегенә ныклы бәйләнмәгән вакытлыча ( шул исәптән күчмә), инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташмаган сәүдә ноктасы;

**төзекләндерү объектлары**-җирдә ясалма капламлар (асфальт-бетон, бетон катлам), иҗтимагый-эшлекле, торак һәм рекреацион зоналарда җир өслегенең башка өлешләре, биналар һәм корылмалар булмаган мәйданнар, урамнар, юллар, велосипед юллары, ишегалды эчендәге урын, балалар, спорт һәм спорт-уен мәйданчыклары, хуҗалык мәйданчыклары; җирле әһәмияттәге автомобиль юллары; махсус сакланыла торган табигать объектлары һәм тарихи-мәдәни әһәмияттәге җирләр, зиратларны төзекләндерү элементлары сыйфатында карала торган яшел утыртмалар (агачлар, куаклар, газон һ. б.); тышкы яктырту һәм архитектура-сәнгать яктырткычларын урнаштыру; коймалар, капкалар, балалар, спорт һәм спорт-уен мәйданчыклары объектлары; бәйрәм үткәрү һәм башка бизәлеш предметлары; территорияне санитар яктан тәртиптә тоту өчен билгеләнгән урыннар, җиһазлар һәм корылмалар, шул исәптән чүп-чар җыю һәм чыгару өчен җиһазлар һәм корылмалар; җитештерү зоналарын һәм аерым җитештерү объектларын төзекләндерү объектлары сыйфатында карала торган объектлар, инженерлык инфраструктурасы зоналары, махсус билгеләнештәге зоналар, шулай ук тиешле санитар-сак зоналары; аерым торак биналарның, җитештерү һәм инженерлык корылмаларының тышкы кыяфәте; субъектларның гамәлләре законнарда билгеләнгән төзекләндерү кагыйдәләре һәм нормалары белән җайга салына торган башка объектлар;

**стационар булмаган объектларны, ясалма төзекләндерү объектларын урнаштыру, юллар төзү һәм ремонтлау, биналар, корылмалар, яшелләндерү буенча чаралар, инженерлык коммуникацияләрен төзү, үзгәртеп кору һәм ремонтлау белән бәйле җир эшләре алып бару буенча мәҗбүри таләпләр** - билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән рөхсәт һәм проект документлары, махсус оешмалар белән килешүләр һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү, санитар нормаларны үтәү һәм дәүләт һәм муниципаль стандартлар нигезендә муниципаль берәмлек территориясенең эстетик торышын саклау буенча чаралар комплексын үтәү;

**яшелләндерү**-шәһәр тирәлеген үсемлек компонентларыннан актив файдалану юлы төзекләндерү һәм ландшафт оешмасы, шулай ук инженерлык төрләре буенча эшләр (вертикаль планлаштыру, терраса төзү һәм башкалар) һәм агачлар, шул исәптән эре агачлар, куаклар утырту юлы белән яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү, газоннар, чәчәк үсентеләре, альпинарийлар һәм рокарийлар булдыру, махсуслаштырылган бакчалар һәм һ. б. белән бәйле комплекслы эшчәнлек;

**гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр**-төрле ял итү формалары өчен билгеләнгән урыннар (урман парклары, бакчалары, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары);

**чикләнгән территорияләрнең яшелләндерелгән территориясе**-дәвалау, балалар укыту һәм фәнни учреждениеләре, сәнәгать предприятиеләре, спорт комплекслары, торак кварталлар;

**махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр**-санитар зоналар, су саклау зоналары, зиратларны яшелләндерү, питомниклардагы үсентеләр;

**ордер** -җир һәм төзелеш эшләрен башкаруга хокук бирүче документ;

**махсус сакланучан табигать территорияләре** - җирле үзидарә органнары карарлары белән тулысынча яки өлешчә хуҗалык кулланyуыннан алынган һәм алар өчен махсус саклау режимы билгеләнгән табигый комплекслар һәм объектлар урнашкан аерым табигатьне саклау, фәнни, мәдәни, эстетик, рекреацион һәм сәламәтләндерү әһәмияткә ия булган объектлар урнашкан җир участоклары, су өслеге һәм һава;

**җәмәгать транспортын көтү тукталышы**-җәмәгать транспорты тукталышлары, пассажирларны утырту һәм төшерү зонасы һәм җәмәгать транспорты пассажирларын көтү зонасы булган махсус җиһазландырылган мәйданчык;

**пыяла фасад**- фасадның бөтен яссылыгын яки аның шактый өлешен биләп торучы тоташ пыяладан эшләнгән фасад;

**ачык яктырту ысулы**- яктылык чыганагы мәгълүмати конструкцияләрне каршылыкларсыз яктырта торган ысул;

**пандус-** аз хәрәкәтләнүче төркемнәр һәм сәламәтлеге чикләнгән гражданнар өчен төрле объектларга үтүне тәэмин итүче баскыч;

**җирлек панорамасы**-ачык пространстводан (яр буе, мәйдан, су объектлары акваториясе, төрле һәм күзәтү мәйданчыклары) кабул ителә торган, җирлекнең характеристикаларын һәм силуэтын ачучы җирлек территориясе өлеше;

**парковка (автомобиль кую урыны)** - автомобиль юлының бер өлеше һәм (яисә) юлның йөрү өлешенә һәм (яисә) тротуарларга, юл кырыйларына, эстакада яки күпернең бер өлеше яисә урам-юл челтәренең башка объектларына һәм транспорт чараларын түләүле нигездә кую өчен махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урын;

**бинаның алгы ягын (фасадын) бизәкләү паспорты**-бердәм архитектура һәм төс чишелешен билгеләүче һәм аерым торучы бинаның фасадын тышкы бизәүгә таләпләрне билгеләүче килешенгән һәм билгеләнгән тәртиптә расланган документ;

**җирлек урамнарының перспективасы-**алдагы фронт һәм урамнар силуэтын барлыкка килгән композиция, стиль һәм сәнгать характеристикалары булган җирлек тирәлеге өлешен визуаль кабул итү;

**җәяүлеләр зоналары**- зур тизлекле җир өсте җәмәгать транспорты тукталышлары, хезмәт күрсәтү объектлары, тарих һәм мәдәният һәйкәлләре,

рекреацияләр, җәяүлеләр агымының күпләп тупланган урыннарында транзит хәрәкәт итү максатларында һәм билгеле бер характеристикаларга ия булган шәһәр территориясенең җәяүлеләр йөри торган участоклары. Җәяүлеләр зоналары эспланадаларда, җәяүлеләр урамнарында, торак пункт мәйданының җәяүле өлешләрендә формалашырга мөмкин;

**җәяүлеләр коммуникациясе**-тротуарлар, аллеялар, юллар, җәяүлеләр бәйләнешен тәэмин итүче сукмаклар. Җәяүлеләр коммуникацияләрен муниципаль берәмлек территориясендә җәяүлеләр өчен элемтә һәм хәрәкәт итүне тәэмин итә. Торак пункт территориясендә җәяүлеләр коммуникацияләрен урнаштырганда транспорт коммуникацияләре белән кисешүнең минималь күләмен, җәяүлеләр коммуникацияләре системасының өзлексез эшләвен, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүен тәэмин итәргә кирәк;

**автостоянка мәйданчыгы**-җиңел автомобильләр һәм башка мототранспорт чаралары (мотоцикллар, мотороллер, мотоколяскалар, мопед, скутерлар) саклау өчен билгеләнгән махсус ачык мәйданчык;

**хайваннарны урамда йөртү һәм өйрәтү мәйданчыгы**-йорт хайваннарын урамда йөртү һәм өйрәтү өчен билгеләнгән территориянең аерым участогы;

**яшел утыртмаларга зыян китерү**- яшел үсентеләрнең җир өсте өлешенә һәм тамыр системасына механик, химик һәм башка зыян китерү, шул исәптән яшел үсентеләрне яки туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату;

**су басу** - елгаларда, сусаклагычларда су арту нәтиҗәсендә грунт суларының артуы,атмосфера явым-төшемнәре, кар эрү, юлларга асфальт-бетон катламын, тротуарларны, инженерлык системаларыннан һәм коммуникацияләрдән су агызуны сыйфатсыз урнаштыру нәтиҗәсендә юл участогы, транспорт тоннельләрен, территорияләрнең бер өлешен су басу. 2 кв. метрдан артык мәйданлы территориия 3 см тирәнлектә су астында калса, ул территорияне су баскан дип санала.

**җирлек территориясе**-муниципаль берәмлек чикләрендәге территория;

**йорт яны территориясе**-шәхси йорт яки күпфатирлы йортка технологик һәм функциональ яктан турыдан-туры бәйләнгән территория;

**якын-тирә территория**- чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән бина, корылма, җир участогы янындагы гомуми файдаланудагы территория;

**продук бирә торган хайваннар һәм кош-корт** - берничә тапкыр яки даими куллану өчен азык-төлек (сөт, йон, йомырка һәм башка) алу өчен асрала торган хайваннар һәм кош-корт;

**төзекләндерү проекты**-текст һәм график формадагы материалларны үз эченә алган, территорияне һәм башка объектларны төзекләндерү буенча проект чишелешләрен билгели торган документлар;

**тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорты)** -төзекләндерү элементының тышкы кыяфәтен һәм урнашу урынын билгели торган муниципаль хокукый акт белән расланган, атап әйткәндә тышкы мәгълүмат чараларын билгели торган һәм аны идентификацияләү өчен кирәкле башка белешмәләрне үз эченә алган билгеле формадагы документ;

**территорияне санитар чистарту**-билгеле бер территориядән каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны җыю, чыгару һәм утильләштерү (зарарсызландыру);

**ут тартмасы**-тышкы мәгълүмат чарасын ясау ысулы, анда конструкция бердәм күләмдә яки эчке яктырткычлы берничә күләмле элементтан гыйбарәт;

**авыл хуҗалыгы хайваннары** - терлекчелек һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен кулланыла торган хайваннар, кыйммәтле мехлы хайваннар, куяннар, умарта кортлары һәм башкалар;

**төзекләндерү объектын карап тоту**-чисталыкны тәэмин итү, төзекләндерү объектларының, аларның аерым элементларының техник, физик, санитар һәм эстетик халәтен тиешле дәрәҗәдә тоту;

**территорияләрне карап тоту**-биналар, корылмалар, кече архитектура формалары, коймалар, төзелеш мәйданчыклары, яшел үсентеләр, җир кишәрлегендә урнашкан транспорт инфраструктурасы объектларын үз вакытында ремонтлау һәм карап тоту белән бәйле чаралар комплексы;

**юлларны, квартал эчендәге юлларны һәм башка юл инфраструктурасын карап тоту**-аларны тиешле тәртиптә һәм чисталыкта тоту, автомобильләр һәм җәяүлеләр юлы, тротуарлар, юллар, урамнар, квартал эчендәге юллар һәм юл хуҗалыгының башка элементларының тоткарлыксыз эшен тәэмин итү буенча чаралар комплексы;

**җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту**-юл, юл корылмаларының, юлларны комплекслы төзекләндерү элементларының транспорт-эксплуатацион торышына ярдәм итә торган эшләр комплексы;

**яңгыр коеларын (яңгыр канализациясен), җир асты коммуникацияләре коеларын (корылмаларын) карап тоту-** яңгыр сулары канализациясенең һәм җир асты инфраструктурасының башка элементларын гамәлдәге дәүләт һәм муниципаль стандартлар таләпләренә туры китереп куллану буенча чаралар комплексы;

**махсуслаштырылган автостоянка**- хуҗасыз транспорт чараларын саклау өчен билгеләнгән һәм махсус җиһазландырылган мәйданчык;

**махсус оешмалар** - муниципаль контрактлар нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү өлкәсендә эшчәнлекнең махсус төрләрен гамәлгә ашыручы, шул исәптән транспорт чараларын махсуслаштырылган машина кую урынына күчерүне гамәлгә ашыручы оештыру-хокукый формадагы юридик затлар;

**транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннар**-закон нигезендә оештырылган автомобиль стоянкалары, гаражлар, ремонт остаханәләре һәм башка биналар, техника саклау (хезмәт күрсәтү) өчен билгеләнгән биналар; Россия Федерациясе Министрлар Советы - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында" 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән парковкалар (парковка урыннары)";

**спорт мәйданчыгы**- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән объектлар (баскетбол щитлары, брусьялары, гимнастик стена, турниклар һәм (яки) башка шундый объектлар урнашкан территория);

**тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы** - оешма урнашкан урында һәм (яки)эшчәнле алып барган урында биналарны мәгълүмати рәсмиләштерү максатларында, кулланучыларга "Кулланучылар хокукларын яклау турында" Федераль законның 9 статьясы нигезендә реклама белән бәйле максатларны эзәрлекләмәгән мәҗбүри булган мәгълүматны җиткерү өчен оешманың фирма атамасы (исеме), аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүмат шулай ук территорияне төзекләндерү элементы булып тора. "Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары" һәм "тышкы мәгълүмат чарасы" төшенчәләре тәңгәл;

**төзелеш мәйданчыгы**-яңа төзелеш (шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары), шулай ук гамәлдәге күчемсез милек объектларын, корылмаларны төзү һәм (яки) монтажлау һәм сүтү, ремонтлау, реконструкцияләү өчен техник яктан яңадан җиһазландырылган урын;

**супер графика**-фасадларны архитектура-сәнгати бизәү алымнарының берсе (рәсем, орнамент, барельеф, мозаика), ул аны визуаль кабул итүне көчәйтә;

**тактиль катлам-**өслек катламының фактурасы сизелерлек үзгәргән катлам;

**каты коммуналь калдыклар**-физик затлар тарафыннан куллану процессында торак урыннарында барлыкка килә торган калдыклар, шулай ук физик затлар тарафыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында торак урыннарында куллану барышында үзләренең куллану үзенчәлекләрен югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган калдыклар да керә;

**гомуми файдаланудагы территорияләр** – барлык кешеләр тоткарлыксыз файдалана ала торган территорияләр (мәйданнар, урамнар, йөрү юллары, яр буйлары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар);

**җирлек территориясенең аерым статусына һәм (яки) югары мәдәни-рекреацион һәм социаль кыйммәткә ия булган өлеше**-әлеге Кагыйдәләр нигезендә, җирлектә барлыкка килгән төзелешенең тышкы архитектура йөзен саклап калу максатларында, тышкы мәгълүмат урнаштыру чаралары төрләре һәм типлары;

**транспорт чарасы**-юл буйлап кешеләрне, йөкләрне һәм җайланмаларны ташу өчен билгеләнгән җайланма (тагылмалар, ярымприцеплар һәм транспорт чарасы белән хәрәкәт итү өчен кирәкле башка җайланмалар);

**территорияләрне җыештыру**-җитештерү һәм куллану калдыкларын, башка чүп-чар, карны махсус билгеләнгән урыннарга җыю, чыгару белән бәйле эшчәнлек төре, шулай ук халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә һәм әйләнә-тирә мохитне саклауга юнәлтелгән башка чаралар;

**күрсәткечләр**- биналарның алгы ягына урнаштырылган урам исемнәре, йортлар, подъезд һәм фатир номерлары, янгын гидранты, грунт геодезик билгеләре, магистраль камералар һәм сүүткәргеч челтәр коелары, шәһәр канализациясе, җир асты газүткәргеч корылмалары, полигонометрик билге, инвалидлар өчен объектның үтемлелеген күрсәтүче билгеләр;

- туризм объектлары, мәгариф объектлары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында гомумиләштерелгән мәгълүмат булган күрсәткечләр;

**урамнар һәм уртак авыл юллары** - җирлек тирәлеге эстетикасына югары таләпләр куела торган гомуми файдаланудагы территорияләр;

**вәкаләтле органнар**-үз компетенциясе кысаларында җирлек территориясен төзекләндерү эшен оештыру, координацияләү һәм тикшереп тору эшен башкаручы муниципаль берәмлекнең функциональ һәм территориаль органнары;

**чүп савыты (урна)** -чүп җыю өчен 0,2 кубометрдан 0,5 кубометрга кадәр күләмле махсуслаштырылган савыт (чиләк, тартма һәм башка шундый савытлардан тыш);

**фасад -бинаның тышкы ягы** (төп, ян, ишегалды). Бинаның төп фасады иң күренеп торган зона, кагыйдә буларак, үзәк һәм/яки башка әһәмияттәге урамнарны күрүгә юнәлдерелгән;

**фриз** -фасадның яки козырекның горизонталь рәвештәге декоратив элементы;

**фронтон**-бинаның соңгы каттагы тәрәзәләренең өске ягыннан фасадның иң өстенә кадәрге өлеше;

**хуҗалык мәйданчыклары**-йорт яны территориясендә хуҗалык өчен билгеләнгән мәйданчык, келәмнәрне һәм йорт кирәк-яракларын чистарту, чүп җыю өчен махсус җиһазландырылган урын;

**төзекләндерү элементлары**-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, корылмалар, кече архитектура

формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр;

**төзекләндерү объектлары элементлары**-төзекләндерү объектларының тышкы күренешен билгели торган конструктив һәм функциональ өлешләре, төзекләндерү объектларын күрә кабул итүне тәэмин итә торган, шулай ук аларның функциональ билгеләнеше нигезендә төзекләндерү объектларын куллану (файдалану);

**яшелләндерү элементлары**-сәнәгать һәм торак төзелеше, иҗтимагый-административ үзәкләрдә, шулай ук урамнарда һәм магистральләрдә яшелләндерү өчен билгеләнгән территорияләр;

**өслек элементлары** – борт ташларының төрле төрләре, пандуслар, баскычлар.

## II.Территорияләрне төзекләндерүгә, карап тотуга һәм җыештыруга гомуми таләпләр

6. Төзекләндерү, карап тоту һәм җыештыру җирлек территориясе һәм анда урнашкан барлык биналар (шул исәптән торак йортлар) һәм корылмаларга (алга таба - биналар, корылмалар) кагыла.

7. Гомуми файдаланудагы территорияләрне, шул исәптән урамнар, юллар, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, яр буе, скверлар, пляжлар, башка объектларны, җир кишәрлекләрен карап тотуны һәм җыюны оештыруны вәкаләтле органнар үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра.

8. Физик һәм юридик затлар (алга таба - җир кишәрлекләренә ия булучылар), аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, милек хокукында, бүтән әйбер яки мәҗбүри хокукта булган җир кишәрлеген, шулай ук биналарны, корылмаларны мөстәкыйль рәвештә яки махсус оешмаларны үз акчалары хисабына җәлеп итү юлы белән гамәлдәге законнарда һәм әлеге Кагыйдәләрдә каралган күләмдә җыештыралар һәм карап тоталар.

8.1. Бина, корылма милек хокукында яки башка әйбер яисә мәҗбүри хокукта булган очракта, җыештырылырга тиешле территория затлар арасында милек хокукында яки күчемсез милек объектына башка хокуктагы өлешкә пропорциональ билгеләнә.

8.2. Җир кишәрлеге территориясендә төрле затларга караган берничә бина, корылма булса, территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре якларның килешүе буенча билгеләнә ала.

8.3. Килешү булмаганда, җыештырылырга тиешле территория барлык милекчеләр яки биналарның, корылмаларның хуҗалары (кулланучылары) арасында тигез өлешләрдә билгеләнә.

8.4. Физик яки юридик зат карамагында булган җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, җир кишәрлеге фактта барлыкка килгән чиге буенча җыештырылырга тиеш.

8.5.Әгәр бина, корылма милек яки берничә кешедә мәҗбүри хокукта булса, фасадны карап тоту яклар килешүе буенча билгеләнә ала.

8.6. Килешү булмаганда, фасадны карап тоту милек хокукындагы яки күчемсез милек объектына башка хокуктагы өлешкә пропорциональ рәвештә башкарыла.

9. Җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, бакча ширкәтләре һәм башка хуҗалык итүче субъектлар каты көнкүреш калдыкларын җыю, саклау һәм чыгару буенча килешүләр төзергә һәм калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыруны башкаручы махсуслаштырылган предприятиеләр белән килешү мөнәсәбәтләре булган чүп-чар ташучы оешмаларга үз вакытында түләргә тиеш.

9.1. Башкаручылар белән территорияне, шул исәптән беркетелгән, якын-тирә территорияне җыештыруга, чүп-чар һәм кар чыгаруга шартнамәләр төзегән затлар башкаручылардан  эшне үз вакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруны таләп итәргә тиеш.

9.2.Авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, шәхси йорт хуҗалары, бакча ширкәтләре һәм башка хуҗалык итүче субъектлар түбәндәгеләргә бурычлы:

1) территорияне төзекләндерү өчен янәшәдә чүплекләр, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар, контейнер мәйданчыклары булуны, ә канализация булмаган биналарда, корылмаларда һәм төзелмәләрдә сыек калдыклар өчен җыентыклар (ташландык су чокыры) булдыруны тәэмин итәргә; контейнерларга, контейнер мәйданчыкларына ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2) авыл территориясендә контейнерларны төзек хәлдә тотуны тәэмин итәргә, контейнерлар тулып ташымаска һәм территорияне пычратмаска тиеш;

3) үз вакытында, аена кимендә бер тапкыр, чүплекләрне, контейнерларны, контейнер мәйданчыкларын, сыек калдыклар өчен җыентыкларны (ташландык су чокырын) чистартуны һәм дезинфекцияләүне тәэмин итәргә;

4) җитештерү һәм куллану калдыкларын чыгаруны оештыруны һәм аларны юк итү графигын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

5) чүп савытларын, контейнерларны, контейнер мәйданчыкларын үз вакытында буярга һәм юарга.

9.3.Каты көнкүреш калдыкларын җыю, саклау һәм чыгару буенча килешүне башкару урынында сакларга һәм  территориясендә юридик зат яки шәхси эшмәкәр булган УК, ТСЖ язма таләбе буенча, Кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тотучы затларга күрсәтергә кирәк.

10. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын, тротуарларны карап тоту һәм җыештыру тәэминатчыны (подрядчы, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләре буенча, әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контрактлар төзегән махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен карап тоту һәм җыештыру күпфатирлы йортлар белән идарә итүнең кайсы да булса бер ысулына туры китереп башкарыла: торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы идарәче оешма (алга таба - идарәче оешмалар).

12. Шәхси торак йортларның территорияләрен карап тоту һәм җыештыру бу йортларның милекчеләре (яллаучылар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Яшелләндерү һәм төзекләндерүне карап тотуны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

1) бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә-җир кишәрлегенең милекчеләре яисә башка хокук ияләре;

2) гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә-тәэминатчыны (подрядчы, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эшләр башкаруга муниципаль контракт төзегән вәкаләтле орган яисә оешма;

3) чикләнгән файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр (предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр) һәм махсус билгеләнештәге (санитар зоналар, су саклау зоналары, зиратлар, питомниклар) чикләрендә-әлеге объектларның хуҗалары;

4) йорт яны территорияләре чикләрендә - күпфатирлы йортларда торак биналарның милекчеләре яки идарәче оешмалар;

5) җир өсте коммуникацияләренең, шул исәптән электр челтәрләре, яктырту челтәрләре, радиолинияләр сак зоналарында-күрсәтелгән коммуникацияләрнең хуҗалары;

6) җир асты коммуникацияләренең сак зоналарында (әгәр урнаштыру рөхсәт ителгән булса) - күрсәтелгән коммуникацияләрнең хуҗалары.

14. Урам һәм юллардан җир асты һәм өслек суларын агызу өчен билгеләнгән кюветларны, торбаларны, дренаж корылмаларын чистарту, яңгыр канализациясе коллекторларын һәм яңгыр коеларын чистарту аларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

15. Җәмәгать бәдрәфләрен урнаштыру һәм карап тоту тәртибе гамәлдәге законнар, санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә билгеләнә. Аларның санитар һәм техник торышы өчен милекчеләре, хуҗалары, арендалаучылар яки махсус оешмалар җаваплы.

16. Төзекләндерү эшләрен башкаруның вакыты, тиешле санитар һәм техник торышын тәэмин итүне исәпкә алып, эшләрнең заказчысы тарафыннан билгеләнә.

17. Җирлек территориясен карап тоту һәм җыештыру чикләре физик һәм юридик затлар тарафыннан бирелгән җир кишәрлеге чикләре нигезендә билгеләнә (әгәр җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән булса, асылда, җир кишәрлегенең барлыкка килгән чиге буенча).

18. Вәкаләтле орган җирлек территориясен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә карап тоту һәм җыештыру эшләренең үтәлешен контрольдә тота.

## III. Биналар, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренең тышкы кыяфәтен, фасадлар һәм коймалар, юллар, шәхси торак йортлар, яңгыр канализациясе челтәрләре, яңгыр коесы, су җибәрү корылмалары, техник элемтә чаралары, тышкы яктырту объектлары, кече архитектура формалары, стационар булмаган объектлар, төзелеш эшләре, җирләү урыннары, автотранспорт чараларын озак вакытлы һәм кыска вакытлы саклау стоянкаларын карап тоту буенча таләпләр. Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү

### Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тоту буенча гомуми таләпләр

19. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тотуны милекчеләр яки башка хокук ияләре мөстәкыйль рәвештә махсус оешмаларны үз акчалары хисабына җәлеп итү юлы белән гамәлгә ашыра.

20. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) биналарның, корылмаларның фасадларын карап тоту;

2) җир кишәрлеген җыештыру һәм санитар-гигиеник чистарту;

3) гражданнар, оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә торган җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю һәм чыгару;

4) җир кишәрлегендә урнашкан яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын карап тоту һәм тәрбияләү, милектәге, биләгән яки файдаланудагы җир кишәрлекләрендә Сосновский балтырганын юк итү;

5) керү урыннары козерекларын үз вакытында кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән арындыру, кәрнизләрне, балконнарны һәм лоджияләрне, агач кәүсәләрен һәм ботакларын саклау чаралары күреп, боз катудан чистартып тору;

6) биналарның хуҗалары (арендалаучылар) һәм торак фонды белән идарә итүче оешмалар тарафыннан түбәләрне һәм керү урыннарын кардан, боздан, боз сөңгеләреннән, шулай ук кар өемнәреннән үз вакытында чистартып тору;

7) тышкы су агызулы түбәне кардан карның калынлыгын 30 см дан арттырмыйча чистартып тору, ә җылытканда, кар калынлыгы тагын да югарак булганда чистартылырга тиеш;

8) биналарныңҗ әяүлеләр зоналарына чыга торган түбәләрен кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән, хәтәр урыннарны билгеләнгән нормаларга туры китереп алдан киртәләп алып чистарту;

9) барлык тәр түбәләрдә, шул исәптән балконнар һәм керү урыннары козырекларында кар өемнәре барлыкка килүгә юл куймау;

10) биналарның авыш түбәсен һәм козырекларын, керү урыннарын һәм тәрәзә уемнарын кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән чистарту, аларны урам як тротуарларына тәүлекнең якты вакытында гына ташлау. Калган түбәләрдән, шулай ук яссы түбәләрдән карны эчке ишегалды территорияләренә ташлау зарур. Карны ташлау алдыннан кешеләрнең иминлеген тәэмин итә торган саклык чаралары күрергә кирәк. Бина түбәсеннән гомуми файдаланудагы юлларга һәм юл буена ташланган кар, боз һәм боз сөңгеләре, юлның йөрү өлешен җыештыручы зат белән төзелгән килешү нигезендә, карны чыгару белән бер үк вакытта башкарыла;

11) карны түбәдән һәм керү урыннары козырекларыннан ташлаганда агачларның, куакларның, урам утлары һава линияләренең, растяжкаларның, реклама конструкцияләренең, светофор объектларының, юл билгеләренең, элемтә линияләренең, элмә такталарның тулы сакланышын тәэмин итә торган чаралар күрү.

**Биналарның, корылмаларның фасадларын карап тоту**

21. Бина, корылмалар фасадларының төзелгән өлешендә, декоратив бизәкләү һәм инженерлык элементларында күзгә күренеп торган кимчелекләр булырга тиеш түгел,алар тиешле эстетик калыпта тотылырга тиеш.

22. Биналарның, корылмаларның фасадларын карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) конструктив элементларны һәм фасадларны, шул исәптән керү ишекләрен һәм козырекларны, балкон һәм лоджия, кәрнизләр, болдыр һәм аерым баскычлар, витрина, декоратив детальләрне һәм башка конструктив элементларны үз вакытында ремонтлау һәм буяу;

2)су торбаларының, су агызу корылмаларының төзек хәлдә булуын һәм карап тотуны тәэмин итү;

3) герметизация, җөйләр салу, ярыкларны ремонтлау;

4) керү юлларын, отмосткаларны, цоколь тәрәзәләрен һәм подвалларга керү юлларын үз вакытында ремонтлау һәм чистарту;

5) фасадларны, шул исәптән фасадлар элементларын, аларның торышы һәм куллану шартларына бәйле рәвештә, үз вакытында чистарту һәм юдыру;

6) тәрәзәләрне һәм витриналарны, элмә такталарны һәм күрсәткечләрне вакытында юу;

7) фасадларны язу, рәсемнәр, игъланнар, плакатлар һәм башка мәгълүмати-басма продукциядән, шулай ук граффитидан арындыру.

23. Биналар, корылмалар, төзелгән торак булмаган биналар милекчеләренә, башка хокукка ия булучыларга һәм тиешле вазифалар йөкләнгән башка затларга түбәндәгеләр киңәш ителә:

1) фасадларны кирәк булган саен чистарту һәм юу;

2) тәрәзәләрнең эчке һәм тышкы өслекләрен, балкон һәм лоджия ишекләрен, подъездларга керү ишекләрен химик чаралар белән чистарту һәм юу;

3) фасадның факттагы халәтен исәпкә алып, агымдагы ремонт үткәрү, шул исәптән фасадны буяу;

4) фасадның аерым элементларына (цоколь, керү юлы, баскычлар, керү ишекләре, капка, цоколь тәрәзәләре, балконнар һәм лоджияләр, су торбалары, тәрәзә култыклары һәм башка конструктив элементларга) ремонт ясау;

5) фасадның чыгып торган конструкцияләренә җимерелү куркынычы янаган очракта, сак-кисәтү чаралары оештыру (коймалар, сеткалар урнаштыру, элементның җимерелә торган өлешен сүтү);

6) кулланылышта булмаган тышкы мәгълүматны (элмә такталарны) сүтеп алу (арендалаучы яки субарендалаучы булмаган һәм башка очракларда).

24. Фасадларны кулланганда рөхсәт ителми:

1) биналарның һәм корылмаларның фасадлары өслегенә зыян китерү (пычрату): ярыклар булу, штукатурка коелган урыннар, кирпеч стеналар җимерелгән урыннар, тимер-бетон конструкцияләрнең катламнары кубу һ.б.);

2) панельләр арасында герметизация бозылу;

3) фасад, биналар һәм корылмаларның цоколь өлешендәге штукатурка, буяу катламы кубу, шул исәптән тәрәзә, керү юлларының төзек булмавы;

4) биналарның һәм корылмаларның алгы якка чыгып торган өлешләренә зыян килү (пычрану): балконнар, лоджия, эркерлар, тамбурлар, кәрнизләр һ.б.;

5)балкон, лоджия, парапетлар һ.б. җимерелү (булмау, пычрану);

6) бинаның фасадында һәм (яки) түбәсендә, элмә такталардан, эш режимы турындагы табличклардан тыш, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорты булмаган тышкы мәгълүмат чаралары урнаштыру;

7) афишалар, игъланнар, плакатлар һәм башка мәгълүмати-басма продукцияне фасадларга, тәрәзәләргә (шул исәптән тәрәзәнең эчке ягыннан), ишек пыялаларына элү элү (шул исәптән ишекнең эчке ягыннан);

8) милекчеләренең ризалыгыннан башка күпфатирлы йорт биналарының, корылмаларның фасадларына граффити төшерү.

25. Рөхсәт ителә:

1) подъездларга кергәндә мәгълүмати стендлар урнаштыру;

2)биналар түбәсендә антенналар һәм кабельләр урнаштыру.

**Күрсәткеч билгеләр**

26. Биналарның, корылмаларның фасадлары күрсәткеч билгеләр белән җиһазландырылырга тиеш.

27. Тарихи территорияләр чикләрендә урнашкан биналарда, корылмаларда урам исемнәре һәм номерлары күрсәтелә, шулай ук фасадлары урам һәм юлларга чыга торган биналарда мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә урнаштырыла. Күрсәткечләр һәм номер билгеләре чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш. Аларның чисталыгы һәм төзеклеге өчен биналарны карап тотучылар җаваплы.

**Керү урыннары (узеллар)**

28. Бина, корылмаларның керү юллары яктырту җиһазлары, козыреклар баскычлар, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен пандуслар, тотынгыч корылмалар белән җиһазландырылырга тиеш.

Пандус шумый торган, горизонталь канаулары булмаган материалдан эшләнергә тиеш. Киртәләре булмаган очракта, пандусның 75 мм биеклектәге борты һәм култыксалары булырга тиеш. Бордюр пандусының авышлыгы 1: 12 булырга тиеш.

Пандус борылышлы булганда, аның озынлыгы 9 метрдан да ким булмаска тиеш һәр 9 метр саен 1,5 x 1,5 м үлчәмле горизонталь мәйданчыклар ясалу тәкъдим ителә. Горизонталь участокларны пандус башында һәм ахырында тирә-юньдәге өслекләрдән текстура һәм төс белән аерылып тора торган итеп эшләргә кирәк.

Баскычлар яки пандусның ике ягында да стенадан 40 мм арада 800-920 мм лы ясалган түгәрәк яки турыпочмаклы тоткычлар булырга тиеш. Баскычлар киңлеге 2,5 м һәм аннан күбрәк булганда, бүленгән тоткычлар карала. Тоткычларның озынлыгы пандус яки баскычның озынлыгыннан һәр яктан да 0,3 метрга озынрак булырга тиеш. Кешенең кулы металл конструкцияләргә орынырга тиеш түгел.

29. Керү төркемнәрен проектлаганда биналарның, корылмаларның фасадларын яңарту, үзгәртү түбәндәге очракларда рөхсәт ителми:

1) гомуми файдалану территориясенә чыга торган фасадларда идән югарылыгы җир югарылыгыннан  1,2 м биекрәк урнашкан биналар подвалына һәм цоколь катына керү юллары ясау;

2) җәяүлеләр хәрәкәтенә комачаулый торган терәк элементлар (колонна, стойка һ.б.) урнаштыру;

3) бинаның фасадын комплекслы исәпкә алмыйча һәм проект документларын эшләтмәгән килеш, ике һәм аннан да күбрәк керү юлы урнаштыру (булганнарын исәпкә алып);

4)тротуарлар зонасында урам-юл челтәре минималь киңлектә булганда, тротуарлардан 0,5 метрдан якынрак  итеп  керү юллары элементлары (баскычлар, пандуслар,  яшелләндерү) урнаштыру;

5)күпфатирлы йорт  милекчеләренең ризалыгы булмаса, керү төркеме урнаштыру;

6)торак милекчесе ризалыгыннан башка керү төркемен урнаштыру өчен балконны куллану;

7) күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган бүлмәләрдә керү төркемнәрен вәкаләтле орган белән килештермичә үзбелдекле урнаштыру.

**Түбә**

30. Биналар, корылмалар түбәләре, су бирү системасы элементлары, төтен чыга торган урыннар һәм вентиляция системалары төзек хәлдә булырга һәм теләсә нинди һава шартларында анда яшәүчеләр һәм җәяүлеләр өчен куркыныч тудырмаска тиеш.

31. Кышкы чорда  биналарның милекчеләре һәм башка хокукка ия булучылар, шулай ук күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар тарафыннан түбәләрне кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән вакытында чистартып тору оештырылырга тиеш. Җәяүлеләр зоналарына чыккан якларда түбәне кардан чистарту участокларны киртәләү һәм барлык саклык чараларын күреп һәм бары тик тәүлекнең якты вакытында гына башкарылырга тиеш. Түбәдән, шулай ук яссы түбәдән кар эчке ишегалды территорияләренә ташланырга тиеш. Түбәдән җәяүлеләр юлларына, җәмәгать транспортын көтү тукталышлары янына, машиналар йөри торган өлешенә ташланган кар кичекмәстән җыештырылырга тиеш.

32. Кар, боз сөңгеләре һәм каткан  боз  ташланган вакытта, түбәдә ремонт һәм башка эшләр башкарылганда агач һәм куакларның, электр линияләренең, яктырту һәм элемтә, юл билгеләре, юл светофорларының, юл киртәләренең, җәмәгать транспортын көтү павильоннарының, биналарның декоратив бизәлешенең һәм инженерлык элементларының сакланышын тәэмин итүче чаралар күрелергә тиеш.

Күрсәтелгән элементлар зыян күргән очракта, алар түбәне чистарткан һәм зыян китергән зат хисабына торгызылырга тиеш.

33. Биналарның, корылмаларның түбәләрендә җәяүлеләргә һәм җәяүлеләр зоналарына су турыдан-туры эләгә алмый торган суүткәргечләр булырга тиеш. Су җыю, агызу җайланмалары җәяүлеләр сукмакларыннан читкә чыгарга тиеш.

34. Рөхсәт ителми:

1) биналар, корылмаларның түбәләренә төзелеш материаллары, ремонт калдыклары, файдаланылмый торган башка предметлар (көрәкләр, кыргычлар, ломнар) кую;

2) биналар, корылмалар түбәсендә төзелеш материаллары, ремонт калдыклары, файдаланылмый торган механизмнар һәм башка предметлар (көрәкләр, кыргычлар, ломнар) саклау;

3)биналарның түбәсеннән боз, кар һәм чүп-чарны су торбаларына ташлау.

**Җир кишәрлекләрен карап тоту**

35. Җир кишәрлекләре территорияләрен карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1)чүп-чардан, яфраклардан, кар һәм боздан арындыру;

2) юлларның машиналар йөри торган өлешләрен, күперләрне, урамнарны, тротуарларны, җәяүлеләр зонасын бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү;

3) карны көрәү һәм себерү;

4) кар һәм бозны чыгару;

5) контейнер мәйданчыкларын, калдыкларның барлык төрләре өчен контейнерлар, чүп-чар өчен урналар, эскәмияләр, кече архитектура формалары һәм башкаларны чистарту һәм техник яктан төзек хәлдә тоту;

6) чүп-чарны кабул итү камераларын, контейнерлар (бункерлар) һәм контейнер мәйданчыкларын җыештыру, юу һәм дезинфекцияләү;

7) яңгыр һәм кар суларын читкә агызу;

8)каты көнкүреш, зур габаритлы һәм башка калдыкларны җыю һәм чыгару;

9) территорияне тузаннан арындыру һәм һаваны чистарту өчен су сибү;

10) яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итү, аларны карап тоту; территорияләрдә гражданнар тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затлар милке өчен куркыныч булган корыган һәм аварга торган яшел утыртмаларны вакытында кисү, Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар күрү (химик, механик һәм башкалар).

Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар аңа чәчәк ата башлаганчы гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү, чабу, үскән урыннарны казу, корыганнарын юкка чыгару, тамырын казып чыгару, туфракны эшкәртеп, күпьеллык үлән чәчү юлы белән үткәрелә;

11) коммуналь объектлар, инженерлык коммуникацияләре (корылмалар), юллар, тимер юллар, күперләр, җәяүлеләр кичүендә реставрация, археологик һәм башка җир эшләре алып барылганнан соң бозылган элементларны яңадан торгызу;

12) гамәлдәге дәүләт стандартлары таләпләре нигезендә яңгыр коеларын (яңгыр канализациясен), җир асты коммуникацияләре коеларын (корылмаларын) карап тоту;

13) җир кишәрлекләрен карап тоту, шул исәптән анда урнашкан җимерелгән биналарны, корылмаларны территориягә чит затлар кереп, рөхсәтсез чүп-чар ташлау мөмкинлеге бирмәслек итеп карап тоту, шулай ук аларны вакытында пычрактан, кардан һәм мәгълүмати-басма продукциядән чистартуны тәэмин итү.

## Юлларны карап тоту

36. Юлларны карап тотуны тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен башкаруга муниципаль контрактлар төзегән оешмалар башкара.

37. Юл территорияләрен карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге юлларны ремонтлау;

2) тротуарлардан (җәяүлеләр зоналарыннан) пычрак, чүп-чар, кар һәм бозны чыгару, юлларның йөрү өлешен, ясалма юл корылмаларын җыештыру;

3) юл катламнарын юу һәм су сибү;

4) газон һәм яшел утыртмаларны карап тоту;

5)тышкы яктырту баганаларын, җәмәгать һәм тимер юл транспорты элемтә челтәрен ремонтлау;

6)кече архитектура формаларын ремонтлау һәм буяу;

7) яңгыр коеларын, канауларны һәм ясалма юл корылмалары составына керә торган ачык лотоклар ремонтлау һәм чистарту;

8)коймалар, турникетлар, кече архитектура формалары урнаштыру, ремонтлау һәм ел саен буяу.

9) ачык люкларны, юл катламы бозылган урыннарны ачыклау һәм киртәләр кую максатларында юлларның торышына көндәлек мониторинг.

38. Юл катламнарын саклау максатларында рөхсәт ителми:

1) йөкне сөйрәп ташу;

2) төяү-бушату эшләре вакытында рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, торбалар, кирпеч, башка авыр предметлар ташлау һәм аларны билгеләнмәгән урыннага өеп кую;

3) машиналар йөри торган юлга һәм тротуарларга төзелеш материаллары һәм төзелеш калдыклары ташлау һәм (яисә) өеп кую.

4) транспорт чараларын йорт яны территориясеннән читтә җирлек милкендә булган җирләрдә юу;

5) чылбырлы механизмлы машиналарның каты өслекле юллардан йөрүе;

6) машиналар йөрү өлешенә чагыштырма авырлыгы билгеләнгән нормалардан һәм күрсәтмәләрдән артып киткән авыр йөкле үзйөрешле машиналар һәм механизмнар йөрү;

7) территорияләрне пычратырлык грунт, чүп-чар, коелучы төзелеш материаллары, җиңел тара, яфракларны брезент яки башка материал белән капламыйча ташу;

8) юлларның йөрү өлешенә һәм алар янындагы территориягә кар, боз, пычрак, җитештерү һәм куллану калдыклары ташлау;

9) юлларга, тротуарларга, газоннарга һәм яшел утыртмаларга пычрак, чүп-чар өю;

39.Юлларны төзекләндерүнең аерым элементларына таләпләр:

1) җәяүлеләр юлындагы металл коймаларны һәм тротуар баганаларын сезонлы буяу ел саен кышкы сезон тәмамланганнан соң, төзекләндерү айлыгы үткәрү чорында гамәлгә ашырыла. Буяу алдыннан коймалар ремонтланырга, пычрактан арындырылырга тиеш;

2) юл билгеләре заказчы тарафыннан билгеләнгән вакыт һәм чират тәртибендә юл тамгасы төшерү өчен расланган паспортлар (схемалар) нигезендә үтәлергә тиеш;

3) юл билгеләре таләп ителә торган төс һәм яктылык-техник характеристикаларга, эләктерелеш коэффициентына җавап бирергә, эксплуатацияләү чорында бөтен мәйдан буенча сакланырга тиеш;

4)юл билгеләрен ныгыту конструкцияләре һәм системалары күрү шартларына һәм монтажлау мөмкинлекләренә карап сайлап алына;

5)юл билгеләре төзек хәлдә булырга, вакытында чистартылырга һәм юылырга тиеш.

Вакытлыча куелган юл билгеләре сәбәпләре бетергәннән соң бер тәүлек эчендә юк ителә;

6) коммуникация системасын күрү элементлары: транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте юнәлешләрен күрсәткечләр, җирлекнең планлаштыру-структура элементларын күрсәткечләр юлларда һәм транспорт чишелешләрендә хәрәкәт юнәлешен күрсәтү өчен куела.

**Муниципаль берәмлекнең гомуми файдаланудагы территорияләрен карап тоту һәм төзекләндерү**

40. Муниципаль берәмлекнең гомуми файдаланудагы территорияләрендә түбәндәгеләр тыела:

1) территорияне металл, төзелеш һәм авыл хуҗалыгы продукциясе һәм калдыклары, ягулык-майлау материаллары, нефть продуктлары белән пычрату, чүп-чар ташлау урыннары ясау;

2) махсус билгеләнгән урыннардан тыш, калдыклар һәм чүп-чар җыю өчен контейнерлар урнаштыру;

3) билгеләнгән тәртипне бозып, стационар булмаган сәүдә объектлары, шулай ук ял итү өлкәсендәге хезмәт күрсәтү объектлары (аттракционнар, кабартылган батутлар, велосипедлар прокаты, роликлар һәм халыкның ялын һәм күңел ачуын оештыру өчен файдаланыла торган башка шундый объектлар) урнаштыру;

4) автомототранспорт чараларын махсус билгеләнгән урыннардан читтә юу һәм чистарту;

5) сибелүчән, тузанлы йөкләрне, яфрак, төрле эретмәләрне юлларны пычранудан саклый торган брезент яки махсус җиһазландырылган башка материал белән капланмаган йөк машиналарында ташу;

6) стационар булмаган объектларны үзирекле урнаштыру;

7) җир эшләрен тиешле рөхсәттән (ордер) башка башкару;

8) грунтны, чүп-чар, калдыклар, кар һәм бозны тиешсез урыннарга өю;

9) гамәлдәге законнарны бозып, квартал эчендәге юлларга һәм йортларга керү юлларына, урамнарга, тротуарларга, газоннарга төзелеш материаллары өеп кую;

10) кәгазьләрне, чүп-чар, тәмәке төпчекләрен мәйданчыклар, ишегаллары, паркларда, скверларда һәм башка җәмәгать урыннарында газоннарга, тротуарларга, урам территорияләренә ташлау;

11) бакча утыргычларының аркаларына менеп утыру, эскәмияләрне, урамнарны яктырту фонарьларын, башка кече архитектура формаларын вату, пычрату;

12) яңгыр сулары канализациясе, кювет рәшәткәләренә, кое япкычларына көнкүреш калдыклары ташлау;

13) предприятиеләрнең эчке территорияләрендә һәм шәхси йортларда чүп-чар, яфраклар һәм коры үлән, җитештерү калдыклары, каты коммуналь калдыкларны янгынга каршы чаралар күрмичә яндыру, учак ягу;

14) фасадларны үзбелдекле үзгәртеп кору, барлык типтагы гаражлар урнаштыру, арендада яки милектә булган җир кишәрлекләреннән читтә базлар, утын сарайлары, будкалар, күгәрчен оялары, теплицалар, тирес җыю урыннары һәм башка корылмалар ясау, шулай ук билгеләнмәгән урыннарда кече архитектура формалары кую, тышкы мәгълумат урнаштыру;

15) яшел утыртмаларны сындыру, юк итү, аларга атынгычлар, гамаклар элү, кәүсәләренә кадак кагу;

16) газоннарны бозу һәм юк итү;

17) гамәлдәге законнарны бозып, юлның машиналар йөрү өлешенә кар ташлау;

18) йорт хайваннары, кошларын гамәлдәге законнарны бозып, хуҗасыз рәвештә урамда, авыл хуҗалыгы җирләрендә йөртү (авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләгән җирләрдән тыш);

19) эре габаритлы төзелеш чүп-чарын, көнкүреш техникасы һәм җиһазларын, киселгән агачларны, килешү кәгазе булмаган килеш һәм гамәлдәге законнарны бозып, контейнер мәйданчыкларына ташлау;

20) сүтек транспорт чарасын, авыл хуҗалыгы техникасын, тагылмаларны һәм ярымприцепларны, хезмәт транспортын, шул исәптән дәүләт теркәү номерларыннан башка, гамәлдәге законнарны бозып, урнаштыру һәм саклау;

21) автотранспорт чараларын, хайваннарны, керне чишмә, кое, су колонкалары, елга ярларында, күлләрдә һәм ясалма (декоратив) сулыкларда юу һәм юыну;

22) йорт яны территорияседә, йорт яны кишәрлегеннән читтә тирес өю;

23) йорт яны территориясендә, урамнарда һәм бу максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарда юынтык су түгү, чүп-чар ташлау. Канализацияләре булмаган торак биналарда бәдрәф һәм юынтык сулар җыю өчен, зур предметларның чокырга эләгүенә комачаулый торган стеналары, капчыклары булган һәм җылытылган ташландыклар чокырлары карала.

24) йөк төяү - бушату эшләре алып барганда йөкне сөйрәп ташу, рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, торбалар, кирпеч һәм башка авыр предметларны юл өслегенә өеп кую, чылбырлы механизмлы машиналарның каты өслекле урамнар буйлап йөрүе, квартал эчендәге юлларда зур йөк транспорты йөрү;

25) торак пункт территориясендә автотранспорт тәгәрмәчләреннән балчык һәм пычрак коелу;

26) транспорт чараларын торак пунктлар чикләрендә балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларына, шулай ук йорт

яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларына (газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үләннәр белән шөгыльләнүче башка территорияләрне дә кертеп) кую.

## Шәхси торак йортларны тоту һәм территорияне төзекләндерү

41. Шәхси торак милекчеләре (яки) яллаучылар (алга таба - торак йортлар хуҗалары), әгәр законда яки килешүдә башкасы каралмаган булса, түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

1) торак йортларның фасадлары, коймаларның, шулай ук йорт төзелеше чикләрендә башка корылмаларның тиешле торышын тәэмин итәләр, аларны вакытында ремонтлыйлар һәм буйыйлар;

2) торак йортта билгеләнгән номер билгесе булу;

3) тәүлекнең караңгы вакытында яктырткыч фонарьларны кабызалар ( булганда);

4) йорт төзелеше чикләрендә яшел утыртмаларны тәртиптә тоту, куаклар һәм агачларны санитар кисү, газүткәргечләрнең сак зонасында, кабель һәм һава электр тапшыру линияләрендә һәм башка инженерлык челтәрләрендә агачлар утыртуга юл куймау;

5) канауларны һәм су агызу торбаларын чистарту, язгы чорда кар суы агуны тәэмин итү;

6) бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә үзәкләштерелгән канализация булмаганда, юынтык су чокыры, бәдрәфне санитар нормалар нигезендә даими чистартып тору һәм дезинфекция ясау;

7) каты һәм зур габаритлы калдыкларны махсус мәйданчыкларга урнаштырылган контейнерларга ташлау;

8) йорт территориясен тәртиптә тоталар һәм тиешле санитар торышны тәэмин итү;

9) якын-тирә территориядән карны чистартканда, транспорт, җәяүлеләр йөри алуны, инженерлык коммуникацияләренә һәм корылмаларга керү мөмкинлеген һәм яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итү.

42.Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:

1)йорт яны территорияләрен һәм алар янәшәсендәге территорияләрне чүп үләннәре белән чүпләү;

2)яфракларны, территориядәге һәм йорт биләмәләрендәге теләсә нинди башка калдыкларны һәм чүп-чарны яндыру;

3))йорт яны территориясен төрлечә чүпләү;

4) коймаларны йорт биләмәсе чигеннән чыгарып урнаштыру;

5) территориядә күмер, утын, зур габаритлы калдыклар, төзелеш материаллары саклау;

6) ишегалды корылмаларын, чокырларны йорт биләмәләре чигеннән чыгып ясау;

7) урамда махсус транспорт һәм җыештыру техникасы йөри алуны кыенлаштыра торган каршылыклар тудыру;

8)территорияне төзекләндерү элементларын җимерү һәм бозу, сулыкларны пычрату;

9) йорт биләмәсе чикләрендә төзек булмаган транспорт чарасын саклау;

10)әйләнә-тирә территорияне төрле калдыклар белән чүпләү;

11) сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чарасын, авыр транспорт чарасын, махсус техника, тагылмалар, ярымприцепларны саклау; әйләнә-тирәне теләсә нинди калдыклар белән чүпләү;

12) машиналар йөри торган юлга сыек чистарткычлар, җитештерү һәм куллану калдыкларын чыгару җайланмалары урнаштыру;

13) киселгән агачлар, куаклар, үләннәрне каты көнкүреш калдыкларын җыю мәйданчыкларына ташлау.

Җир кишәрлеге хуҗасы тарафыннан шәхси торак йорт яки хуҗалык корылмалары төзелгән очракта, Башкарма комитетның язмача рөхсәте булганда, Үрнәкавыл җирлеге башлыгы йорт яны территориясендә, шул исәптән урамда төзелеш материалларын вакытлыча бер ай саклауны рөхсәт итә ала. Төзелеш материаллары кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерүне, шулай ук җимерелү, аву яки башка йогынты нәтиҗәсендә өченче затларның мөлкәтенә зыян китерүне булдырмый торган ысул белән урнаштырылырга тиеш. Шул ук вакытта автотранспортның йөрү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

**Яңгыр канализациясе челтәрләрен, яңгыр һәм күзәтү коеларын, су агызу корылмаларын карап тоту**

43. Яңгыр коелары, җир асты коммуникацияләре коелары, люклар (рәшәткәләр) ябык хәлдә булырга һәм транспорт һәм җәяүлеләрнең имин хәрәкәтен тәэмин итәрлек төзек хәлдә булырга тиеш.

44. Яңгыр, тупик, күзәтү коеларын һәм камераларын карап тору, чистарту, төзек хәлдә тотуны гамәлдәге дәүләт стандартлары буенча аларның милекчеләре башкара.

45. Җирлектә яңгыр канализациясенең магистраль һәм квартал эчендәге челтәрләрен карап тоту һәм эксплуатацияләү авыл җирлеге бюджетында каралган акчалар чикләрендә махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Яңгыр канализациясенең ведомство челтәрләрен карап тоту һәм эксплуатацияләү тиешле оешмалар хисабына башкарыла.

Хуҗасыз инженерлык коммуникацияләре һәм күзәтү коелары юлларны карап тотуны гамәлгә ашыра торган махсус оешмалар тарафыннан куркыныч булмаган тиешенчә хәлдә сакланырга тиеш.

46. Яңгыр канализациясе коллекторларын саклау максатыннан, коллектор күчәреннән һәр якка 2 м ераклыкта сак зонасы урнаштырыла.

47. Гамәлдәге законда билгеләнгән очракларда, яңгыр канализациясе коллекторларының сак зонасы чикләрендә тиешле документларны рәсмиләштермичә һәм эксплуатацияләүче оешма, башка органнар белән язмача килешенмичә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

1)җир эшләре башкару;

2) яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен зарарлау, су кабул итү люкларын томалау яки җимерү;

3) сәүдә, хуҗалык һәм көнкүреш корылмалары урнаштыру, төзелеш эшләре башкару;

4) сәнәгать, көнкүреш калдыклары, чүп-чар һәм башка материаллар ташлау.

48. Сууткәргеч, канализация, яңгыр сулары җайланмаларының, системаларның, челтәрләренең һәм корылмаларының төзек булмавы аркасында урамнарны, биналарны, корылмаларны су басу, боз катламы барлыкка килү, шулай ук газоннарга, тротуарларга, урамнарга һәм ишегалды территорияләренә су түгү, кудыру яки агызу рөхсәт ителми.

49. Авыл җирлеге территориясендә су җыю коелары һәм пар мәйданчыклары урнаштыру рөхсәт ителми.

50. Яңгыр коеларының рәшәткәләре даими рәвештә чистартылырга тиеш. Аларның чистарту сәләтен чикли торган рәшәткәләр һәм коелар булу рөхсәт ителми. Яңгыр канализациясен һәм яңгыр коеларын профилактик тикшерү һәм аларны чистарту елына ике тапкырдан да ким булмаган санда башкарыла. Күзәтү һәм яңгыр коеларын чистартканнан соң, чыгарылган барлык калдыклар кичекмәстән ташланырга тиеш.

51. Күзәтү коеларының люклары машиналар йөрү юллары, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, яшел зоналар бер биеклектә булырга тиеш.

Машиналар йөрү өлешендә, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, яшел зоналар белән коелар биеклеге аермасы 2 см дан артмаска тиеш, яңгыр суларын җыя торган коеларныкы 3 см дан да артмаска тиеш.

52. Япкычлары яки рәшәткәләре җимерелгән яки юкка чыгарылган коелар булган очракта, алар кичекмәстән челтәрдән файдаланучы оешма тарафыннан алдан

кисәтүче билгеләр белән билгеләнергә һәм билгеләнгән вакытка алыштырылырга тиеш.

53. Инженерлык челтәрләрендә планлы эшләр вакытында канализация сулары якындагы яңгыр канализациясенә (булган очракта) чыгарыла. Суны юлга агызу тыела.

Су агу нәтиҗәләрен бетерү зыян күргән инженерлык челтәрләре хуҗалары хисабына башкарыла.

Яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең техник торышы (шул исәптән люкларны, рәшәткаларны вакытында ябу) өчен җаваплылык эксплуатацияләүче оешмаларга йөкләнә.

**Техник элемтә чараларын карап тоту**

54. Биналарны инженер-техник тәэмин итү өчен билгеләнгән кабель элемтә, телевидение, радио, интернет һәм башка шундый челтәрләрне урнаштыру җир асты ысулы белән башкарыла (траншеялар, каналлар, тоннельләр).

55. Биналарга тышкы коммуникацияләрне башка ысул белән (һава, җир өсте) урнаштыру, эксплуатацияләүче оешмаларның тиешле техник шартлар алу шарты белән, аларны җир астында урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта гына рөхсәт ителә.

56. Асылмалы элемтә линияләрен һәм һава-кабель юлларын беркетү сыйфатында түбәндәгеләрне файдаланырга ярамый:

1) автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын: юл киртәләре, светофорлар, юл билгеләре урнаштыру өчен билгеләнгән элементлар һәм конструкцияләр;

2)фасадларны, түбәләр, бина стеналарын (төтен чыга торган урыннар, вентиляция, телевидение һәм радио күмәк кабул итү системасы антенналары, фронтоннар, козыреклар, ишекләр, тәрәзәләр).

57. Рөхсәт ителми:

1) бер бинадан икенчесенә һава юлы белән элемтә кабельләре салганда юллар киселеше;

2) кабель запасларын бүлгеч муфта шкафыннан читтә урнаштыру;

58. Милекчеләр (хуҗалар) техник элемтә чараларын (кабельләр, кабельләрне беркетү элементлары, бүлү һәм муфта шкафлары һәм башкалар), шулай ук алар ярдәмендә тиешле хәлдә тоташтырыла торган техник җайланмаларны (кимчелекләрне бетерми һәм/яки изоляция тышчасы булмау, буяу, коррозия һәм/яки механик җәрәхәтләр, чыбыклар чыбыклары чыбыклары һәм/яки аларны яктырту баганаларына һәм электр тапшыру линияләренә карап тотмаска тиеш) тиешле дәрәҗәдә тотарга тиеш.

**Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту**

59. Тышкы яктырту элементларына яктырткычлар, кронштейннар, терәкләр, чыбыклар, кабельләр, тукландыргыч чыганаклар (шул исәптән җыю, тукландыргыч пунктлар, идарә тартмалары) керә.

60. Урамнар, юллар, тротуарлар, торак кварталлар, ишегаллары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар территорияләре, шулай ук аншлаглар һәм җәмәгать һәм торак биналарының номер билгеләре, юл билгеләре һәм күрсәткечләр, җирлек мәгълүматы элементлары һәм витриналар тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.

61. Биналарның һәм корылмаларның милекчеләре, милек формасына карамастан, проектлар буенча биналарның һәм корылмаларның архитектура-нәфис яктыртылуын тәэмин итәргә тиеш.

62. Төп мәйданнарда, магистральләрдә һәм урамнарда, транспорт тоннельләрендә эшләми торган яктырткычлар саны 3% тан артмаска тиеш, башка җирлек территорияләрендә (район әһәмиятендәге урамнар, ишегалды территорияләре) - 5%, җир асты җәяүлеләр кичүләрендә - 10% (10 яктырткычның 1 се эшләмәскә мөмкин).

63.Сафтан чыккан терекөмешле газ разрядлы лампалар әлеге максатлар өчен махсус билгеләнгән биналарда сакланырга тиеш. Файдаланылмаган терекөмешле лампаларны туплау, мондый товарларны эксплуатацияләү кагыйдәләрендә күрсәтелгән терекөмешле лампаларны җитештерүче тарафыннан каралган куркынычсызлык таләпләренә туры китереп башкарыла. Сафтан чыккан зыян килмәгән терекөмешле лампаларны туплау терекөмешле лампаларның сакланышын тәэмин итә торган индивидуаль һәм транспорт төргәкләрендә башкарыла. Сафтан чыккан терекөмешле лампаларны аларга зыян килү мөмкинлеген булдырмау максатларында яңа лампаларның төргәкләрендә туплау рөхсәт ителә.

64.Сафтан чыккан терекөмешле лампаларны туплау әйләнә-тирә мохитне пычратуга һәм кеше тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерүгә юл куймый торган герметик транспорт төргәгендә башкарыла.

Зарарланган терекөмешле лампаларны туплау башка төр калдыклардан аерым башкарыла. Зарарланган һәм зарарланмаган терекөмешле лампаларны бергә туплау рөхсәт ителми.

Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны транспортлау "җитештерү һәм куллану калдыклары турында"Федераль законның 16 статьясы таләпләренә туры китереп башкарыла.

65. Металл терәкләр, кронштейннар һәм тышкы яктырту җайланмаларының башка элементлары чиста булырга, авышу, коррозия элементлары булмаска һәм кирәк булган саен, әмма өч елга бер тапкырдан да ким булмаган санда милекчеләр

(хуҗалары, кулланучылар) тарафыннан буялырга һәм төзек хәлдә булырга тиеш.
66. Бердәм тышкы яктырту системасына тоташтырылган юл, урам һәм йорт яны утларын карап тоту һәм ремонтлауны вәкаләтле орган яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәт күрсәтүгә контракт төзегән махсуслаштырылган оешма башкара.
66. Тышкы яктыртуның бердәм системасына тоташтырылган юл, урам һәм йорт яны яктырткычларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итүне (подрядчы, башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контракт төзегән вәкаләтле орган яки оешма башкара.

67.Торак йортлар тапшыру бүлгечләренә тоташтырган йорт яны утларын карап тотуны һәм ремонтлауны идарәче оешмалар башкара.

68. Тышкы яктырту баганалары, җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә челтәре, саклагыч, бүлү киртәләре, юл корылмалары һәм җиһазлар элементлары буялырга, язулардан һәм теләсә кайсы мәгълүмати-басма продукциядән чистартылырга, төзек хәлдә һәм чиста булырга тиеш.

69. Тышкы яктырту баганаларын, җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә челтәре баганасын алыштырганда күрсәтелгән конструкцияләр сүтелергә һәм челтәр хуҗалары тарафыннан өч тәүлек эчендә чыгарылган булырга тиеш.

Тышкы яктырту баганалары милекче тарафыннан мондый ихтыяҗ булган (сүтү) вакыттан соң 1 тәүлек эчендә чыгарыла.

70. Җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә баганаларында һәм терәкләрдә урнаштырылган барлык элементларның һәм объектларның төзек һәм имин торышы һәм төзек тышкы кыяфәте өчен әлеге терәкләрнең милекчесе җавап бирә.

71. Үткәргечлә өзелгән, терәк, изоляторлар зарарланган очракта тышкы яктырту җайланмаларыннан файдалану рөхсәт ителми.

Тышкы яктырту җайланмалары эшендә электр чыбыклары өзелү яки терәкләр зарарлану белән бәйле җитешсезлекләрне ачыклаганнан соң кичекмәстән бетерергә кирәк.

72. Чыбыкларны һәм кабельләрне челтәрләргә һәм тышкы яктырту җайланмаларына үз белдегең белән тоташтыру рөхсәт ителми.

73. Тышкы яктырту объектлары яки тышкы яктырту чаралары белән җиһазландырылган объектларның милекчеләре (хуҗалары), шулай ук тышкы яктырту объектларына (чараларына) хезмәт күрсәтүче оешмалар:

1) урамнарны, юлларны тиешенчә яктыртуны, терәк һәм яктырткычларның, яктырту җайланмаларының сыйфатын күзәтеп торалар, ватылганда яки зыян күргән очракта үз вакытында ремонтлыйлар;

2) билгеләнгән тәртип нигезендә утны кабызуны һәм сүндерүне күзәтәләр;

3) тышкы яктырткычларны урнаштыру, карап тоту һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтиләр;

4) тышкы яктырту фонарьларын үз вакытында алмаштыралар. Фонарьларның лампаларын алмаштыру төзексезлек ачыкланган яисә халыктан тиешле хәбәр кергәннән соң 10 тәүлектән артмаска тиеш.

74.Тротуарларда урнашкан мачталар һәм тышкы яктырту баганалары һәм җәмәгать транспортының контакт челтәре тирәсен җыештыруны тротуарларны җыештыруга җаваплы затлар башкара.

75.Трансформатор һәм бүлү подстанцияләренә, автомат режимда (хезмәт күрсәтүче персоналдан башка) эшләүче башка инженерлык корылмаларына якын-тирә территорияләрне җыештыруны әлеге объектлар урнашкан территорияләрнең хуҗалары тәэмин итә.

**Кече архитектура формаларын карап тоту**

76. Кече архитектура формаларына монументаль-декоратив бизәү элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү җайланмалары, су җайланмалары, муниципаль җиһазлар, җирлек территориясендәге коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар керә.

77. Кече архитектура формаларын карап тоту бирелгән җир кишәрлкләре чикләрендә гомуми файдалану территорияләрендә тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контракт (килешү) төзегән оешма белән контракт (килешү) нигезендә җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

78.Кече архитектура формалары милекчеләренең бурычлары:

1)кече архитектура формаларын чиста һәм төзек хәлдә тоту;

2) язгы чорда кече архитектура формаларын план нигезендә карап чыгу, аларны иске буяудан, күгәректән арындыру, шулай ук ватылган элементларны алыштыру;

3) кышкы чорда кече архитектура формаларын, шулай ук аларга килү юлларын кар һәм боздан чистарту;

4)тигез өслекле комлыкларны төзекләндерү, комлыкларда елга бер тапкыр комны алыштыру;

5)балалар, спорт, хуҗалык мәйданчыклары һәм ял мәйданчыклары җиһазларының ныклыгы, ышанычлылыгы һәм иминлеге таләпләренә туры килүен күзәтеп тору;

6) фонтаннар эшләгән чорда су өслеген чүп-чардан көн саен чистартып тору.

79. Рөхсәт ителми:

1) кече архитектура формаларыннан тиеш булмаганча файдалану (өлкәннәрнең балалар өчен уен мәйданчыкларында ял итүе, спорт мәйданчыкларында кием киптерү һәм башкалар);

2)теләсә нинди мәгълүмати-басма продукцияне кече архитектура формаларына ябыштыру;

3)кече архитектура формалары һәм аларның конструктив элементларын вату һәм зыян китерү;

4) фонтаннарда коену.

**Стационар булмаган объектларны карап тоту**

80. Стационар булмаган объектларны урнаштыру мондый объектларны муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә урнаштыру схемасы буенча гамәлгә ашырыла.

81. Җир кишәрлеген арендалау килешүе вакыты чыккач, стационар булмаган объект арендалаучы тарафыннан сүтелергә, ә җир кишәрлеге азат ителгән һәм беренчел халәткә китерелгән булырга тиеш.

82. Стационар булмаган объектларның милекчеләре булган юридик һәм физик затлар:

1) ремонт һәм буяу эшләре башкара. Ремонт тышкы кыяфәтне һәм проект документлары белән билгеләнгән төсләр чишелешен исәпкә алып башкарылырга тиеш;

2) якын-тирә территориядә яшел утыртмалар, газоннар, бордюр ташлары, кече архитектура формаларының (булганда) сакланышын күзәтәләр, әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә мондый территорияне карап тоталар;

3) стационар булмаган объектлар янында урналар куялар, кирәк булганда, чүплекләрне көн дәвамында, әмма тәүлегенә кимендә бер тапкырдан да ким булмаган санда чистарталар, елына кимендә бер тапкыр буйыйлар.

83. Рөхсәт ителми:

1) стационар булмаган объектларга козыреклар, өскормалар һәм проектларда каралмаган башка конструкцияләр өстәп төзү;

2) стационар булмаган объектлар янында сәүдә-суыту җиһазлары кую;

3) стационар булмаган объектлар янында һәм аларның түбәләрендә таралар, товарлар, детальләр, көнкүреш һәм җитештерү характерындагы башка әйберләр саклау, шулай ук стационар булмаган объектларны склад максатларында куллану;

4)стационар булмаган объектлар арасында янгынга каршы чокырларны (разрыв) төрле җиһазлар, калдыклар белән тутыру.

**Төзелеш эшләре башкару урыннарын карап тоту**

84. Төзелеш мәйданчыкларын һәм алар янындагы территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзелеш һәм башка төр эшләр тәмамланганнан соң төзекләндерүне торгызу төзүчегә йөкләнә.

Эшләр алып барылмый торган төзелеш объектлары төзелеш челтәрләре белән капланырга тиеш.

85. Төзелеш, ремонт һәм башка төр эшләр башланыр алдыннан, шулай ук төзелеш, ремонт һәм башка төр эшләрне башкару чорында түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

1) төзелеш мәйданы территориясенең бөтен периметры буенча «Төзелештә хезмәт куркынычсызлыгы. 1 өлеш. Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча Россия Федерациясе дәүләт комитетының 23.07.2001 ел, № 80 карары белән расланган гомуми таләпләр" дигән темага семинар-киңәшмә;

2) төзелеш мәйданчыгы коймаларының гомуми тотрыклылыгын, ныклыгын, ышанычлылыгын, эксплуатацияләү иминлеген тәэмин итәргә;

3) төзелеш мәйданчыгы коймаларының тиешле техник торышын, аның кардан, боздан, мәгълүмати-басма продукциядән һәм граффитидан вакытында чистартылуын күзәтеп торырга;

4) төзелеш мәйданы территориясенә кергәндә, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә җавап бирүче мәгълүмати щит урнаштырырга һәм аны тиешле хәлдә тотарга;

5) төзелеш мәйданы периметры буенча тышкы яктыртуны тәэмин итәргә;

6)төзелеш мәйданына илтүче юлларны төзекләндерергә, мәйдан эчендәге юлларны һәм чыгу урыннарында транспорт чаралары тәгәрмәчләрен чистарту һәм юу пунктлары җиһазларга; урамнарның (юлларның) йөрү өлешенә пычрак һәм чүп-чар чыгармаска;

7) төзелеш мәйданчыгы территориясендә каты коммуналь, эре габаритлы һәм төзелеш калдыклары җыю өчен контейнерлар һәм (яки) бункерлар булуны тәэмин итәргә;

8) каты коммуналь, эре габаритлы һәм төзелеш калдыкларын төзелеш мәйданыннан билгеләнгән тәртиптә чыгаруны оештыруны тәэмин итәргә;

9) төзелеш мәйданыннан һәм территориядән чыгарылган карны билгеләнгән тәртиптә килештерелгән махсус билгеләнгән урыннарга ташуны тәэмин итәргә;

10) эшләр башкарганда гамәлдәге җир асты инженерлык коммуникацияләрен, тышкы яктырту челтәрләрен, яшел утыртмаларны һәм кече архитектура формаларын саклауны тәэмин итәргә.

86. Төзелеш материаллары, җиһазлар, автотранспорт һәм күчмә механизмнар, ярдәмче бүлмәләр, эшчеләр һәм хезмәткәрләрне вакытлыча урнаштыру өчен көнкүреш вагончыклары, төзелеш калдыкларының транспорт партияләрен вакытлыча саклау һәм туплау урыннары төзелеш оешмалары проекты нигезендә төзелеш мәйданчыклары чикләрендә урнаштырыла.

87. Рөхсәт ителми:

1) 23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр, гражданнарның шәхси һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү белән бәйле коткару, авария-торгызу һәм башка кичектергесез эшләрдән тыш, торак зонасы янында төзелеш, ремонт, төяү-бушату һәм тынлыкны бозу белән бәйле башка эшләр оештыру һәм үткәрү;

2) җирлек башкарма комитетының тиешле рөхсәтеннән (күрсәтмәләреннән) башка юлларның машиналар йөрү өлешен һәм тротуарларны тарайту яки ябу;

3) чүп-чарны яндыру һәм төзелеш калдыкларын утильләштерү;

4) җир, чүп-чар, төзелеш материаллары, җиңел тараны брезент яки башка юлларны пычратмый торган материаллар белән капламыйча ташу, шулай ук төзелеш катнашмаларын һәм эретмәләрне (шул исәптән цемент-ком эремәсен, известь, бетон катнашмаларын) аларны юлга, тротуарга, юл читенә яки юл янындагы газон полосасына агызу булдырмый торган чаралар күрмичә генә транспортлау.

## Җирләү урыннарын карап тоту

88. Җирләү урыннарын этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә карап тоту федераль законнар һәм муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

89. Җирләү урыннарын санитар тәртиптә тотуны вәкаләтле орган яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәт күрсәтүгә контракт төзегән махсуслаштырылган оешма башкара.

90. Җирләү урыннарын карап тотуга карата таләпләр:

1) зиратлардагы җәмәгать бәдрәфләре чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш. Җәмәгать бәдрәфләре территорияләрендә урналар чистартылган булырга тиеш;

2) зират территориясендә калдыклар өчен контейнерлар һәм чүплекләр чистартылырга тиеш. Калдыклар тулган саен, кимендә 3 көнгә бер тапкыр чыгарылырга тиеш;

3) җимерелгән һәм аварга торган агачларның булуы рөхсәт ителми. Аварга торган агач ачыкланганнан соң бер тәүлек эчендә ул юк ителергә тиеш;

4) шәхесләре ачыкланмаган яки карап тотылмаган каберләр пычрактан һәм чүп-чардан чистартылырга, калкулык һәм кабер ташы белән җиһазландырылырга тиеш.

91. Кышкы чорда җирләү урыннарын карап тоту үзенчәлекләре:

1) зиратларның үзәк юллары, керү юллары, тротуарлар киңәйтелергә һәм кардан чистартылырга тиеш. Бозы булмаган тигез кар катламы булу рөхсәт ителә;

2) үзәк юллар, керү юллары, тротуарлар бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә тиеш. Юл һәм тротуарларның машиналар йөрү өлеше кар явып үткәннән соң ук эшкәртелә башларга тиеш;

3) беренче чиратта карны үзәк һәм керү юлларыннан чыгару, бозны вату һәм кар-боз катнашмасын чыгару зарур;

4) җирләү урыннарында җәяүлеләр зонасында бозлавыкка каршы материаллар куллану, юллардан чистартылган кар һәм бозны каберләргә, газоннарга, куакларга өеп кую рөхсәт ителми.

92. Җәйге чорда җирләү урыннарын карап тоту үзенчәлекләре:

1) үзәк юллар, керү юллары, тротуарлар, каберләр арасындагы юллар һәм җирләү урыннарында башка гомуми файдаланудагы территорияләр төрле пычрактан чистартылырга тиеш;

2) яшел утыртмаларны санитар кисү, чүп булып үскән үсемлекләрне юк итү чаралары ел саен башкарылырга тиеш.

93. Күмү урынын, кабер өстендәге корылманы (тәреләр, һәйкәлләр, плитәләр, склеплар һ.б.) карау, чәчәкләр һәм декоратив куаклар утырту, аны карап тоту, мәҗбүри санитар таләпләрне үтәп, вафат булган затның ире (хатыны), туганнары, законлы вәкиле яки башка зат тарафыннан башкарыла.

**Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау стоянкаларын карап тоту**

94. Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннары гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук әлеге Кагыйдәләр нигезендә стоянкалар урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлеге милекчесе (алга таба - хуҗасы) тарафыннан башкарыла.

95. Милекченең бурычлары:

1) стоянканың бөтен периметрын механик йогынтыларга һәм тышкы мохит йогынтысына тотрыклы булган коймалап кую;

2) стоянка коймаларының тиешле техник торышын, аларның пычрактан, кардан, боздан, мәгълүмат-басма продукциядән вакытында чистартылуын тәэмин итү;

3) стоянка территорияләрендә һәм аңа якын территорияләрдә материаллар, сүтелгән транспорт, төрле конструкцияләр саклау рөхсәт ителми;

4) стоянка территорияләрен гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр таләпләренә туры килә торган тигез яктылыклы тышкы яктырткыч белән җиһазлау;

5) стоянка территорияләрендә ягулык-майлау материаллары агып торган автомобильләр кую һәм автомобильләрне юу рөхсәт ителми;

6) стоянка территорияләрендә санитар һәм янгынга каршы кагыйдәләрне үтәү.

7) стоянка территорияләрен даими рәвештә санитар эшкәртү һәм чистарту, калдыкларны җыю өчен контейнерлар (чүплекләр) кую, каты коммуналь калдыкларны, карны даими рәвештә чыгаруны тәэмин итү;

8) инвалидларның стоянкалар территориясенә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү һәм инвалидларның махсус автотранспорт чараларын кую өчен кимендә 100/0 урын (әмма бер урыннан да ким булмаган санда) бүлеп бирү (анда башка автотранспорт чараларын кую тыела). Инвалидлар "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә махсус автотранспорт чараларын парковкалау урыннарыннан бушлай файдаланалар.

**Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү**

96. Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү дәүләт һәм башка бәйрәмнәр, истәлекле вакыйгалар белән бәйле чаралар үткәрү вакытында башкарыла.

Бәйрәмчә (вакыйга) бизәү чараларга бәйле рәвештә дәүләт һәм муниципаль флаглар, лозунглар, гирляндалар, афишалар, паннолар урнаштыруны, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар, трибуналар, эстрада урнаштыру, шулай ук бәйрәм (вакыйгалар) яктырткычларын (утлы гирляндалар һәм элементлары, сеткалар, күләмле яктылык композицияләре, ут проекцияләре һ.б.) үз эченә ала. Бәйрәм (вакыйга) бизәлеше конструкцияләре аерым торучы бина һәм (яки) корылма фасадындагы конструкцияләр рәвешендә урнаштырыла ала.

Бәйрәмчә бизәлеш элементларын ясаганда һәм урнаштырганда юл хәрәкәтен көйләүнең техник чараларын төшерергә, җимерергә һәм аларны күрү мөмкинлеген начарайтырга ярамый.

**IV. Җирлек территорияләрен чистарту тәртибе, төзекләндерү эшләре исемлеге һәм аларны үтәү, җирлек территориясен җыештыру һәм карап тотуга карата гомуми таләпләр**

97. Җирлек территориясен җыештыру һәм карап тоту вакыты:

1) җәйге чорда - 15 апрельдән 14 октябрьгә кадәр;

2) кышкы чорда-15 октябрьдән 14 апрельгә кадәр.

Әлеге срокларга һава шартларына бәйле рәвештә Башкарма комитет тарафыннан төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

97. Авыл җирлеге территориясен җыештыру үткәрү юлы белән башкарыла торган эшләр:

1) җирлек территориясен карап тоту, җыештыру буенча системалы эшләр;

2) Башкарма комитетның хокукый актлары нигезендә бердәм массакүләм чаралар (өмәләр).

98. Җәйге чорда җирлек территориясен җыештыру, юу, су сибү һәм башка эшләр башкару максатыннан башкарыла торган эшләр:

1)ясалма өслекле территорияләрне сиберү (коры һава шартларында су сибү), урам-юл челтәре объектларының, ясалма өслекле, яңгыр канализациясе белән тәэмин ителгән башка территорияләрнең тузанын һәм юл катламнарын юдыру. Юл катламнарын, мәйданнарны, тротуарларны һәм ясалма өслекле башка территорияләрне юу катламның бөтен киңлегендә башкарыла;

2) яңгыр сулары канализациясенең рәшәткәсен чистарту;

3) чүпне бөтен территориядән җыю;

4) ел саен 1 июньгә кадәр кече архитектура формаларын, бакча һәм урам җиһазлары, урналар, спорт һәм балалар мәйданчыклары, коймалар, бордюрларны буяу;

5)гомуми файдаланудагы территорияләрдә даими рәвештә үләнне чабу (үлән 15 см дан артык озынлыкта булганда), файдаланылышы чикләнгән һәм махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләрдән тыш, чабылган үләнне тәүлек эчендә җыештыру;

6) тәүлегенә бер тапкыр коелган яфракларны җыю һәм чыгару;

7)юганнан соң бордюр лотокларын чүптән арындыру.

100. Гомуми файдаланудагы территорияне кышкы чорда җыештыру:

1)юл өслекләрен һәм тротуарларны кардан, боздан һәм чүп-чардан чистарту;

2) тайгак яки бозлавык булганда җәяүлеләр зоналарына, баскычларга ком сибү, юл катламнарын бозлавыкка каршы материал белән эшкәртү;

3) язгы чорда карны көпшәкләндерү һәм кар суларын агызуны оештыру.

101. Җирлек территориясендә башкарыла торган җыештыру эшләренең технологиясе һәм режимы һава шартларына бәйсез рәвештә транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итәргә тиеш.

102. Кышкы чорда тротуарларны, җир өсте кичүләрен, баскычларны җыештыру үзенчәлекләре:

1) кар күп яуган чорда тротуарлар, җир өсте кичүләре, баскычлар бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә һәм чистартылырга тиеш;

2) бозлавыкка каршы материаллар белән беренче чиратта баскычлар, аннары тротуарлар эшкәртелә.

3)бозлавыкка каршы материаллар  белән эшкәртү вакыты бозлавык барлыкка килү ачыкланганнан соң  дүрт сәгатьтән дә соңрак башкарылмаска тиеш;

4)пычрак калдыклар һәм химик реагентлар белән пычранмаган көпшәк карны, яшел утыртмаларны  сакланганда һәм кар  суларын агызуны тәэмин иткәндә, газон яки бу максатлар өчен алдан билгеләнгән урыннарга өяргә рөхсәт ителә.

103. Җирлек территориясендә рөхсәт ителми:

1) урамнарны, мәйданнар, яшел утыртмалар булган урыннар, скверлар, парклар, газоннар, пляжлар һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләрне чүпләү;

2) гамәлдәге законнар нигезендә җирләү урыннарыннан читтә гомуми файдалану территорияләрендә мемориаль корылмалар (истәлекле корылмалар, чардуганнар) урнаштыру;

3) әлеге максатлар өчен каралмаган урыннарда, шул исәптән муниципаль җәмәгать транспорты маршрутларының соңгы пунктларында салонны юу, чистарту һәм транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү;

4) биналар һәм корылмалар, һәйкәлләр, мемориаль такталар, агачлар, куаклар, кече архитектура формалары һәм башка төзекләндерү элементларын җимерү һәм зыян китерү, шулай ук аларны үзбелдекле үзгәртеп кору һәм урнаштыру;

5) җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, стеналарда, баганаларда, коймаларда (киртәләрдә) һәм бу максатлар өчен каралмаган башка объектларда мәгълүмат-басма продукция, граффити урнаштыру;

6)бирелгән җир кишәрлекләре чикләреннән һәм (яки) киртәләреннән читтә күчемле мөлкәт саклау;

7) сәнәгать товарларын һәм башка сәүдә предметларын тротуарларда, газоннарда, юлларда урнаштыру;

8)карны  билгеләнмәгән урыннарда өю;

9) тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар куеп, юл һәм тротуарларны үзбелдекле ябып  кую.

10) калдыкларны, чүп-чарны һәм башка төрле калдыкларны турыдан-туры кырларга, бакчаларга, урманнарга, сазлыкларга, паркларга, газоннарга, су объектларына һәм аларның яр буе сак полосаларына һәм башка билгеләнмәгән урыннарга чыгару һәм ташлау. Чүп-чар ташлаганда машина йөртүченең үзе белән, хәрәкәт маршрутын һәм калдыкларны тапшыру урынын күрсәтеп, документлары булырга тиеш. Маршруттан тайпылу рөхсәт ителми.

Җирлек территориясендә калдыклар (чүп-чар, кар, җир һ.б.) моның өчен билгеләнгән урыннардан читтә ташланган очракта, мондый хокук бозуларга юл куйган затлар ачыкланган җитешсезлекләрне 10 көннән дә артмаган срокта бетерү буенча чаралар күрә.

104. Рөхсәтсез урыннарда калдыклар ташлаган затлар әлеге территорияне үз хисабына җыештырырга һәм чистартырга, кирәк булганда, җир кишәрлеген рекультивацияләргә тиеш. 20 тәүлек эчендә калдыкларны ташлаучы кеше табылмый икән, аларны юкка чыгару әлеге территорияне җыештыру өчен җаваплы оешмага йөкләнә.

105. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә (территорияләрдә) барлыкка килгән рөхсәтсез чүплекләрне бетерү вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин ителә.

**Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын җыештыру**

106. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (алга таба - юллар) җыештыру машиналар йөрү өлешен, тротуарларны, туктау урыннарын, җәмәгать транспортын көтү тукталышларын (парковка кесәләрен), ясалма юл корылмаларын даими чистарту, кар һәм боздан арындыруны үз эченә ала.

107.Язгы-җәйге чорда юлларны җыештыру юуны, су сибүне, тузанны бетерүне үз эченә ала.

Көзге-кышкы чорда юлларны җыештыру чүп-чардан, кар һәм боздан арындыруны, юлларга ком-тоз катнашмасы сибүне, тротуарларга коры ком сибүне күздә тота.

108. Юл буенда урнашкан чүп савытларын чистарту көненә бер тапкырдан да ким булырга тиеш түгел, ә тукталыш мәйданчыкларында көнгә ике тапкыр башкарыла.

109.Җәмәгать транспортын көтү павильоннары юылган, буялган, рөхсәтсез ябыштырылган мәгълүмати-басма продукциядән, граффитидан арындырылган булырга тиеш. Кышкы чорда кардан чистартылырга тиеш.

110. Аерым элементлар буенча юлларны җәйге җыештыру буенча таләпләр:

1) машиналар йөрү өлеше төрле пычрактан тулысынча чистартылырга тиеш. Җайга салу линияләре белән билгеләнгән күчеш, резерв полосалары ком һәм вак чүп-чарлардан даими чистартылырга тиеш;

2) ике метрлы лоток зоналары комлы һәм пычрак булырга тиеш түгел. Махсус машиналарның эш цикллары арасында ком һәм төрле вак-төяк чүп-чар белән берникадәр пычрану рөхсәт ителә.

3) юл кырыйлары зур габаритлы калдыклардан һәм башка чүп-чарлардан чистартылырга тиеш;

111.Юлларны кышкы җыештыру буенча таләпләр:

1) кышкы чорда юлларны җыештыру түбәндәгеләрне үз эченә ала:

2)юлларның машина йөрү өлешен, җәмәгать транспортын көтү тукталышларын кардан һәм боздан чистарту, карны себерү, өеп кую һәм чыгару;

112. Рөхсәт ителми:

1) юл йөрү өлешен җыештыручы зат белән килешү булмаганда һәм шулай ук 8.00 сәгатьтән соң тротуарларга, юллар һәм аларның машиналар йөри торган өлешенә квартал эчендәге юллардан, ишегалды территорияләреннән, предприятие, оешма территорияләреннән, төзелеш мәйданчыкларыннан, сәүдә объектларыннан кар чыгару;

2) тротуарларда, җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, паркларда, скверларда, ишегалларында һәм башка җәяүлеләр зоналарында һәм яшел утыртмалар булган территорияләрдә бозлавыкка каршы реагент сыйфатында техник тоз һәм сыек хлорлы кальций куллану;

3) пычрак ком-тоз катнашмаларын, шулай ук ватылган бозны газоннарга, чәчәклекләргә, куакларга һәм башка яшел утыртмаларга салу;

4) карны билгеләнгән тәртиптә килештерелмәгән урыннарга өю;

5) кар өемнәре ясау:

6) юллар һәм урамнар киселешендә бер биеклектә һәм тимер юлны аркылы чыгу урыннары янында өчпочмаклы күз күреме зонасында;

7) җәмәгать транспортын көтү тукталышыннан 20 метрга якынрак;

8)транспорт коймалары яки биек бордюр белән җиһазландырылган юл участокларында;

9) тротуарларда;

10) якын-тирә территорияләргә керү юлында;

11) автомобиль тәгәрмәчләре белән пычрату;

12)грунт, чүп-чарны, юеш төзелеш материалларын, киселгән агачларны брезент яки юлларны пычратуны булдырмый торган башка материал белән капламыйча ташу, шулай ук төзелеш катнашмаларын һәм эретмәләрне (шул исәптән цементлы-комлы эремәне, известь, бетон катнашмаларын) транспорт белән чыгару.

**Ял итү урыннарын төзекләндерү һәм җыештыру**

113. Ял итү һәм кешеләр күп җыела торган урыннарга түбәндәгеләр керә:

1) җирлек урманнарында, пляжларда оештырылган мәйданнар, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары;

2) актив ял итү һәм тамаша чаралары урыннары-стадионнар, уен комплекслары, сәхнә мәйданчыклары һәм башкалар;

3)сәүдә объектлары территорияләре (ваклап сату базарлары, сәүдә комплекслары, стационар булмаган ваклап сату челтәре объектлары

комплекслары), җәмәгать туклануы, социаль-мәдәни билгеләнештәге, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары территорияләре;

4) административ һәм иҗтимагый биналар, учреждениеләр янындагы территорияләр.

114.Паркларны, скверларны, бульварларны, яр буйларын һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләрне җыештыру:

- кышкы чорда паркларда, бакчаларында, скверларда, бульварларда һәм башка ял итү зоналарында юлларны чистартканда, яшел үсентеләрнең сакланышы һәм кар сулары агуны тәэмин иткән очракларда, алдан ук шушы максатлар өчен билгеләнгән урыннарга вакытлыча кар туплау рөхсәт ителә.

115. Ваклап сату базарларын җыештыру һәм санитар карап тоту:

1) ваклап сату базарлары территорияләре (алга таба - базар) төзекләндерелергә, бәдрәфләр, хуҗалык һәм контейнер мәйданчыклары, контейнерлар һәм урналар белән җиһазландырылырга, аларда каты өслек һәм яңгыр һәм кар сулары агу урыны, шулай ук суүткәргеч һәм канализация булырга тиеш;

2) базар территориясен төп җыештыру аны япканнан соң башкарыла. Көндез каты көнкүреш калдыклары белән тулган чүп җыйгычларны чистарталар;

3) елның җәйге чорында базар территориясендә мәҗбүри рәвештә атна саен юеш җыештыру башкарыла;

4) базар территориясе чүп савытлары белән 40 кв. м мәйданда бер урна исәбеннән җиһазландырыла, шул ук вакытта алар арасында прилавка линиясе буйлап ара 10 метрдан артмаска тиеш;

116. Базар территориясендә һәм аның янында урнашкан оешмалар, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, киосклар, сәүдә палаткалары һәм павильоннары эшчәнлеге каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төземичә генә эшләве рөхсәт ителми.

117. Сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы урыннарын җыештыру һәм санитар карап тоту:

1) сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектлары территорияләрен тулысынча җыештыру тәүлегенә ике тапкырдан да ким башкарылырга тиеш). Көндез калдыклар белән тулган чүплекләр һәм чүп җыйгычлар чистартыла;

2) сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектларына керү юлында икедән дә ким булмаган бертөсле чүп савыты куела;

3) вакытлыча урам сәүдәсе урыннарында якындагы территория 10 м радиуста чистартыла. Контейнерларны һәм товарларны газоннарда һәм тротуарларда сакларга рөхсәт ителми.

4) калдыкларны вакытында чыгару тәэмин ителә.

118.Башка сәүдә мәйданчыклары, стационар булмаган ваклап сату челтәре, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар территорияләрен җыештыру елның җылы вакытында алар ябылганнан соң башкарыла. Агымдагы җыештыру көн дәвамында башкарыла. Көндәлек көнкүреш калдыкларын чыгару тәэмин ителә.

119. Халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү:

1) кешеләрнең күпләп ял итү һәм яшәү урыннары территориясендә төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге каты өслекләрдән, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп-чар өчен урналар һәм контейнерлар, урам техник җиһазлары, яктырту җиһазлары, архитектура-декоратив яктырту җиһазлары, яшелләндерү участокларын, саклау элементларын (металл коймалар, махсус каплагычлар) үз эченә ала;

2) кешеләр күпләп ял итә торган һәм күңел ача торган барлык территорияләрдә, пляжлардан тыш, каты өслек яки утыртылган үлән яки яшел утыртмалар булырга тиеш;

3) ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган территорияләрдә яшелләндерү участокларын чәчәк түтәлләре, газоннар, ялгыз яки төркемле үсемлекләр, вертикаль, күп яруслы үсемлекләр белән яшелләндерүнең мобиль формалары рәвешендә планлаштырырга кирәк;

4) кешеләр күпләп ял итү һәм күңел ачу урыннары эшли торган бәдрәф кабиналары белән тәэмин ителергә тиеш;

5)фонтан, буалар, елга ярлары, ял итү урыннары пычранган саен чистартылырга тиеш;

6)массакүләм чаралар үткәргәндә, аларны оештыручылар чараны үткәрү урынын җыештыруны һәм төзекләндерү эшләрен торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Чараны үткәрү урынын җыештыру һәм төзекләндерү эшләрен торгызу тәртибе чараны үткәрүгә тиешле рөхсәт алу стадиясендә билгеләнә.

120. Халык күпләп ял итә торган территорияләрдә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

1) билгеләнмәгән урыннарда сәүдә җиһазлары саклау;

2)территорияне җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;

3) автотранспорт чараларын юу һәм ремонтлау, файдаланылган ягулык-майлау сыеклыкларын агызу;

4) автостоянкалар, гаражлар, аттракционнар оештыру, билгеләнгән тәртипне бозып реклама конструкцияләре урнаштыру;

5) газоннар, табигый һәм ясалма яшелләндерү объектларын зарарлау;

6) кече архитектура формалары күчерү һәм вату;

7) су, квас һәм сыра цистерналарыннан сыек продукт калдыкларын тротуарларга, газоннарга һәм юлларга агызу;

8) автотранспорт чаралары өчен рөхсәтсез түләүле парковкалар оештыру;

9)стационар булмаган объектларны үзбелдекле урнаштыру;

10) тротуарларның асфальт-бетон өслеген, якын-тирә яшел зоналарның һәм территорияләрне төзекләндерүнең башка элементларының бөтенлеген бозу;

11) территориядә сәүдә-суыткыч җиһазлары урнаштыру;

12) идарәче оешмалар белән каты коммуналь калдыкларны җыю өчен килешү булмаса, халыктан каты коммуналь калдыкларны җыю өчен билгеләнгән контейнерларга (бункерларга) чүп-чар тутыру;

13) тротуарларны корылмалар һәм башка җайланмаларның тимер-бетон блоклары, багана, коймалар, шлагбаумнар урнаштыру юлы белән рөхсәтсез каплау;

14) сәүдә объектыннан читтә товар кую;

15) учак ягу, шул исәптән ачык ут куллануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар куллану.

**Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен җыештыру, карап тоту һәм төзекләндерү**

121. Йорт яны территориясен җыештыру:

1)җыештыру түбәндәге тәртиптә үткәрелергә тиеш: тротуарларны, җәяүлеләр юлларын (бозлавык һәм тайгак булган очракта - ком сибү), ә аннары ишегалды территорияләрен җыештыру;

2) җыештыру, кар яву вакытында башкарыла торган кар чистартудан тыш, эшләр 8.00 сәгатькә кадәр башкарыла.

Механикалаштырылган җыештыруны машина 4 км/сәг. тизлектә барганда, көндезге вакытта үткәрергә рөхсәт ителә.

122. Җәйге җыештыру:

1) йорт яны территорияләрен җәйге җыештыру: себерү, юу яки су сиптерү, махсус машиналар ярдәмендә күбесенчә иртән, соң, кичке сәгатьләрдә башкарылырга тиеш;

2) тротуарларның лотоклы полоса белән чиктәш ачык урыннарын гына һәм биналардан урамның машиналар йөрү өлешенә таба юнәлештә юарга кирәк;

3) көннең эссе вакытында тротуарларга су сибү кирәк булган саен, әмма тәүлегенә кимендә ике тапкыр башкарылырга тиеш.

123. Кышкы җыештыру:

1) түбәләрдә тупланган кар вакытында җиргә ташланырга һәм лотоклы полосага салынырга, ә киң тротуарларда - өемнәргә җыелырга тиеш;

2) җыештырыла торган кар тротуарлардан машиналар йөри торган өлешкә - лотоклы полосага, ә ишегалларында-җыелу урыннарына салынырга тиеш;

3) квартал эчендәге юллардан чыгарылган карны борт ташына параллель рәвештә урнашкан өемнәргә салырга яки роторлы кар чистарткычлар ярдәмендә юл буйлап урнаштырырга кирәк;

4) 6 метрдан артык киңлектәге тротуарларда, урамнарның машиналар йөри торган өлешеннән газоннар белән аерып алынган урыннарда карны алга таба чыгару өчен тротуар уртасына таба салырга рөхсәт ителә;

5) тротуарларда карны өемнәргә салу кар явып узганнан соң алты сәгатьтән дә соңга калмыйча, ә калган территорияләрдә 12 сәгатьтән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш;

6) ишегалларында, квартал эчендәге юлларда, газоннарда һәм җәяүлеләрнең ирекле хәрәкәтенә һәм автотранспортның йөрүенә комачауламый торган ирекле территорияләрдә, яшел зоналарны саклаганда һәм кар суларын агызуны тәэмин иткәндә, ком-тоз катнашмалары белән пычранмаган карны салу рөхсәт ителә;

7) тротуарларны һәм квартал эчендәге юлларны кулдан чистартканда кар тулысынча кырып җыелырга тиеш. Камилләштерелгән өслекләр булмаганда, аны алга таба тыгызлау өчен кар катламы калдырып җыештырырга кирәк;

8) тайгак булганда, юл катламнарын ком-тоз катнашмасы белән эшкәртү норма буенча метрга 0,2-0,3 кг исәбеннән сиптереп башкарылырга тиеш;

9) бозлы урыннарны чистартканнан соң барлыкка килгән калдыклар газонга, агачлар астына яисә ачык грунтка эләкмичә чыгарылырга тиеш.

124. Яз җитү белән башкарыла торган эшләр:

1) кар суларын агызу өчен кирәк булган канауларны юдырту һәм чистарту;

2) кар суын системалы рәвештә люкларга һәм яңгыр челтәренең кабул итү коеларына кудырту;

3) кар эреп беткәннән соң ишегалды территорияләрен калган кардан, боздан һәм чүп-чардан чистарту.

125. Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен карап тоту:

1) күпфатирлы йортның йорт яны территориясен (алга таба-йорт яны территориясен) карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

2) даими җыештыру;

3) люкларны ремонтлау һәм чистарту, кар һәм яңгыр сулары коеларын, дренажларны рәшәткәләү;

4) янгын вакытында инженерлык челтәрләренең күзәтү коеларын су белән тәэмин итү чыганакларына (гидрантларга, сулыкларга һ.б.) тоткарлыксыз керү мөмкинлеген булдыру;

5)каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыклары җыю һәм чыгару;

6) яшелләндерү һәм булган яшел утыртмаларны тәрбияләү;

7) кече архитектура формаларынын карап тоту, агымдагы һәм капиталь ремонт эшләре башкару.

126. Калдыкларның барлык төрләре контейнер мәйданчыкларына куелган су үткәрми торган капкачлы контейнерлар һәм бункерларга тиешле нормаларга туры китереп һәм тиешле күләмдә салынырга тиеш.

127. Күпфатирлы йортларда яшәүче гражданнарның бурычллары:

1) йорт яны территорияләрендә чисталык һәм тәртип сакларга;

2) каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны йорт яны территорияләрендә урнашкан махсус контейнерларга һәм махсус мәйданчыкларга гына ташларга.

128. Идарәче оешмалар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар урнаштыру, канализациясез биналарда сыек көнкүреш калдыклары өчен җыентыклар ясау;

2) каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны расланган график нигезендә чыгару;

3) контейнерлар (бункерлар) һәм контейнер мәйданчыкларын, аларга керү урыннарын чиста һәм төзек хәлдә тоту;

4) подъездларга керү юлларын чүп-чардан арындыру, эскәмияләр урнаштыру һәм аларны вакытында чистарту;

5) тайгак участокларны ком - тоз һәм (яки) бозлавыкка каршы махсус катнашмалар белән эшкәртү;

6) яшел утыртмаларны һәм газоннарны саклау һәм карап тоту;

7) тышкы яктырту чараларын төзек хәлдә тоту һәм аларны караңгы төшү белән кабызу.

129. Йорт яны территориясендә рөхсәт ителми:

1)яфракларны, калдыкларның теләсә нинди төрләрен һәм чүп-чарны яндыру;

2) кием-салым, келәмнәр һәм башка предметларны хуҗалык мәйданыннан читкә элеп кую;

3) контейнер мәйданчыкларына керү юлларын каплау;

4) урам һәм юлларның машиналар йөри торган өлешенә, тротуарларга, газоннарга һәм яшел зоналарга контейнерлар (бункерлар) кую;

5) билгеләнгән тәртипне бозып, йорт яны территорияләренең коймаларын үзбелдекле урнаштыру;

6) ишегалды корылмаларын үзбелдекле төзү;

7) йорт яны территориясен металл, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары һәм материаллар, шлак, көл һәм башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;

8) ташландык сулар түгү, калдыклар һәм чүп-чар ташлау;

9) автотранспорт чараларын кую өчен түләүле стоянка оештырыру;

10) тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар, объектлар, корылмалар һәм башка җайланмалар урнаштыру юлы белән квартал эчендәге юлларны рөхсәтсез каплау;

11) автомашиналар юу, ягулык һәм майлау материалларын агызу, тормоз һәм двигательләр ремонтлау, тавыш көйләү эшләре башкару;

12)кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган теләсә нинди эшләр башкару;

13)сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре, палаткалар, киосклар, лареклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектлары, автомобильләр, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләре, автостоянка урнаштыру;

14) транспорт белән йорт яны территориясенең ишегалды эчендәге юлларыннан бару;

15) учак ягу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар куллану.

16) ел фасылына карамастан, транспорт чараларын, шул исәптән сүтелгән (төзек булмаган) яшелләндерелгән территорияләргә, балалар, спорт һәм хуҗалык мәйданчыкларына кую.

Тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган

мәҗбүри таләпләрне бозмасалар, стационар булмаган сәүдә объектлары урнаштырырга мөмкин.

130. Идарәче оешмалар тәэмин итәргә тиешле эшләр:

1) яшел зоналарның  саклнышын һәм бөтенлеген тәэмин итү;

2)җәй көне коры һава шартларында  газон, чәчәк түтәлләре, агачлар һәм куакларга су сибү;

3) төзелеш материалларын, ком, чүп-чар, кар  һәм  боздан арындырып, газоннарның сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү;

4) агач һәм куакларны юллар челтәрен үзгәртү һәм җиһазлар урнаштыру белән бергә, агротехник шартларны үтәп, билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проектлар буенча гына утырту.

131. Йорт яны территориясен төзекләндерү:

1) һәр йорт территориясендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

2) кием-салым, келәмнәр һәм көнкүреш әйберләре киптерү өчен хуҗалык мәйданчыгы;

3) өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыгы;

4) балаларның җәйге һәм кышкы ялы өчен кирәкле  яшелләндерелгән, кече архитектура формалары булган,  кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән уен һәм спорт мәйданчыклары.

132. Әгәр территориянең күләме мөмкинлек бирә икән, участок чикләрендә этләрне йөртү өчен мәйданчык булырга мөмкин.

133. Йортлар подъездлары каршындагы мәйданчыклар, юлның машиналар йөрү өлешләре һәм җәяүлеләр юллары каты өслекле булырга тиеш. Каты өслек ясаганда кар һәм яңгыр сулары агып китү  мөмкинлеге каралырга тиеш.

134. Торак йортларга урнаштырылган җәмәгать билгеләнешендәге биналарданың йортның торак өлешеннән изоляцияләнгән керү юллары булырга тиеш, шул ук вакытта персонал автотранспорты ишегалды территориясеннән читкә куелырга тиеш.

135. Җәмәгать өчен билгеләнгән биналарга тәрәзәләр һәм фатирларга керү урыннары урнашкан торак йорт ишегалды ягыннан материаллар, продукция төяү рөхсәт ителми. Төяү эшләрен торак йортларның тәрәзәләре булмаган  ян ягыннан, җир асты тоннельләреннән яки ябык дебаркадерлардан, юллар ягыннан башкарырга кирәк.

136. Транспорт чараларын квартал эчендәге территорияләрдә урнаштыру кешеләр, шулай ук җыештыру һәм махсус техника йөрерлек булырга тиеш.

## Шәхси торак төзелеше территорияләрен җыештыру

1376. Торак йорт хуҗалары җир кишәрлеген көн саен җыештыралар (шул исәптән кардан), үләнне вакытында чабалар (15 см дан артык озынлыкта булганда) һәм чабылган үләнне тәүлек дәвамында җыялар.

138. Рөхсәт ителми:

1) йорт биләмәсеннән читкә кар чыгару, чүп-чар ташлау, йорт тирәсенә сыек көнкүреш калдыклары агызу;

2) кар һәм ватылган бозны ишегалды территориясеннән юлларның йөрү өлешенә чыгару;

3) йорт территориясеннән читтә төрле калдыклар һәм чүп-чар яндыру;

4) йорт яны территориясендә үзбелдекле коймалар кую;

5) якын-тирә территорияне металл, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары һәм материаллар, шлак һәм көл һәм башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;

6) юлларны корылмалар һәм башка җайланмаларга тимер-бетон блоклар, багана, коймалар, шлагбаумнар урнаштыру юлы белән үзбелдекле каплау;

7) кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган теләсә нинди башка эшләр башкару.

## Территорияне төзекләндерү элементларына таләпләр

139. Территорияне төзекләндерүнең аерылгысыз компоненты булган территорияне төзекләндерү элементлары булу гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп проект документларында эшләнергә һәм каралырга тиеш.

Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында урнашкан территорияне төзекләндерү элементларына проект документлары мәдәни мирас объектларын саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә вәкаләтле органнар белән килештерелә.

Территорияне озак яки даими файдаланудагы стационар төзекләндерү элементлары аларны кулдан күчерү мөмкинлеген булдырмас өчен беркетелергә тиеш.

140. Төзекләндерү элементларын карап тоту, аларны торгызу һәм ремонтлау эшләрен дә кертеп, төзекләндерү элементлары хуҗалары башкара.

## Яшелләндерү

141. Яшел үсентеләр территорияне төзекләндерүнең мәҗбүри элементы булып тора.

Төзекләндерү эшләрен башкарганда яшел үсентеләрне мөмкин кадәр саклап калырга кирәк.

142. Җирлек территориясендә яшелләндерүнең ике төре кулланылырга мөмкин: стационар - үсемлекләрне грунтка утырту һәм мобиль - махсус күчмә савытларга утырту (контейнерлар, вазоннар һ.б.)

Стационар һәм мобиль яшелләндерү архитектура-ландшафт объектларын (газоннар, бакчалар, чәчәк түтәлләре, куаклар һәм агачлар) төзү өчен рельефның табигый һәм ясалма элементларында, түбәләрдә (түбә яшелләндерү), биналарның һәм корылмаларның фасадларында (вертикаль яшелләндерү) кулланалар.

143. Яшелләндерү объектларын карап тоту - ул яшел утыртмаларны һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү элементларын  карап тоту, зур булмаган деформацияләрне һәм күләмле корылмаларның конструктив элементларын килгән зыянны бетерү, шулай ук җәйге һәм кышкы чорда күчмә кече формаларны җыештыру эшләре комплексы.
Яшелләндерү объектларында эшләр башкаруга карата таләпләр:
1) яшелләндерү объектлары янында төзелеш мәйданнарын оештырганда проектта билгеләнгән яшел утыртмаларның бөтенлеген саклау буенча чаралар күрергә кирәк. Агачларның аскы киң ботакларын кисү, агач кәүсәләрен саклау максатында бәйләү, киртәләп алу, куаклар ябалдашларын бәйләү, юллар һәм транспорт чаралары һәм башка техника стоянкалары янында урнашкан утыртмалар астындагы җиргә    тыгызланмасын өчен вак таш салу;
2) территорияне вертикаль планлаштыру, җир асты коммуникацияләрен салу, юллар , тротуарларны төзекләндерү яшелләндерү алдыннан төгәлләнергә тиеш;
3) туфрак катламын бозу белән бәйле ремонт, төзелеш һәм башка эшләр башкарганда туфракның уңдырышлы катламын читкә алып торырга һәм аны киләчәктә файдалану өчен сакларга кирәк. Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару тәмамланганнан соң, бозылган җир кишәрлекләрен һәм утыртмаларны яңадан торгызырга кирәк. Торгызу эшләре  эшләр башкару проектында каралырга тиеш;
4) яфракларны һәм үләнне күчкә җыярга һәм киләчәктә компост ясарга яки билгеләнгән тәртиптә чыгарырга кирәк.
144. Яшелләндерү объектларын карап тоту - яшел утыртмаларны һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү, зур булмаган кимчелекләрне бетерү, шулай ук җәйге һәм кышкы чорда күчмә кече формаларны җыештыру.

Яшел утыртмалар хуҗаларының  бурычлары:

1) яшел утыртмаларның сакланышын һәм аларны квалификацияле карауны тәэмин итү;

2) елның җәй айларында коры һава шартларында газоннар, чәчәк түтәлләре, агачлар һәм куакларга су сибүне тәэмин итү;

3)газоннарның сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү;

4) сулыклар булган очракта, яшелләндерү объектларында аларны чиста тотарга һәм аларны 10 елга бер тапкырдан да ким булмаган  ешлыкта капиталь чистарту;

145. Яшелләндерелгән территорияләрдә рөхсәт ителми:

1) эшчәнлеген һәм хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен билгеләнгән төзелешләрдән тыш, төзелеш эшләре башкару;

2)үзбелдекле агач һәм куаклар утырту, газоннарны һәм чәчәклекләрне юк итү;

3)агачларга һәм башка яшел утыртмаларга гамак, таган, турниклар, кер юу өчен бау, реклама һәм мәгълүмат щитлары һәм табличкалар, реклама һәм башка мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән  конструкцияләр, объектларга хәрәкәт итү юнәлешен күрсәтүче билгеләр, афишалар, белдерүләр, агитация материаллары, техник конструкцияләр, юл хәрәкәтендә катнашучыларны мәгълүмати тәэмин итү чаралары элү;

4)ел фасылына карамастан, стационар булмаган объектлар, шулай ук юл сервисы объектлары урнаштыру;

5) төзелеш һәм башка материаллар, калдыклар, чүп-чар, бозлавыкка каршы материаллар һәм башка зарарлы матдәләр, шулай ук ком һәм бозлавыкка каршы реагентлар белән пычранган кар, боз булу;

6)бакчалар казу;

7) йорт хайваннарын газоннарында һәм чәчәк түтәлләрендә йөртү;

8) яфракларны, үләнне, ботакларны яндыру, шулай ук аларны лотокларга һәм башка су үткәрү җайланмаларына тутыру;

9) чүп-чарны газоннарга ташлау;

10) учак ягу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар куллану;

11) агачларны сок, сумала чыгару өчен кисү, аларга башка механик җәрәхәтләр ясарга;

12) яшелләндерү территорияләрендә урнашкан скульптураларны, эскәмияләрне, коймаларны, урналарны, балалар һәм спорт җиһазларын җимерү;

13) агачларның тамырларын кәүсәсеннән 1,5 метрдан да якын  казу һәм агачларның муентыкларын җир яки төзелеш калдыклары белән күмү.

14) транспорт чараларын газоннарга һәм чәчәклекләргә кертеп кую, мәҗбүри торгызу эшләрен башкару шарты белән әлеге территорияләрдә кирәкле эшләрне башкару очракларыннан тыш.

**Коймалар**

146. Коймалар урнаштыру төзекләндерүнең өстәмә элементы.

147. Коймалар түбәндәге төрләрдә була:

1) билгеләнеше буенча (декоратив, саклагыч, аларның берлеге);

2) биеклеге буенча (тәбәнәк-1,0 м, урта-1,1-1,7 м, биек-1,8-3,0 м);

3) материалның төре (металл, тимер-бетон һәм башкалар).);

4) күз күреме дәрәҗәсе буенча (үтә күренмәле, күренми торган);

5) стационар дәрәҗә (даими, вакытлы, күчмә) һәм башка төрле коймалар.

Коймаларны проектлау аларның урнашу урынына һәм гамәлдәге дәүләт стандартларына, сертификацияләнгән эшләнмәләр каталогларына, индивидуаль проектларга туры китереп башкарыла.

148. Мәдәни мирас объектлары территорияләрен койма белән әйләндереп алуны әлеге территорияләр өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә башкарырга кирәк.

**Өслек капламнары**

149. Өслек капламнары җирлек территориясендә имин һәм уңайлы хәрәкәтне тәэмин итә, шулай ук җирлек төзелешенең архитектур йөзен формалаштыра.

Төзекләндерү максатлары өчен түбәндәге капламнар билгеләнгән:

1) каты (капиталь) капламлар-монолит яки җыелма капламнар, шул исәптән асфальт-бетоннан, цемент-бетоннан, табигый ташлардан;

2)табигый яки ясалма сибелүчән материалдан (шул исәптән ком, вак таш, керамзит, резина) башкарыла торган йомшак капламнар-табигый халәттә, тыгызланган яки ныгытылган материаллы коры катнашмалар;

3)газон капламнары - үлән капламын әзерләү һәм утырту буенча махсус технологияләр буенча башкарыла торган каплам;

4) капламнар берләшкән катнаш капламнар (рәшәткәле плитка яки газон рәшәткәсе, газонга күмелгән яки йомшак каплам).

150. Каплам төрләрен сайлап алуны аларның максатчан билгеләнеше нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк:

1) каты- проектлау вакытында гамәлдә булган янгынга каршы таләпләрне исәпкә алып, мөмкин булган чик йөкләнешне, характерны һәм хәрәкәт составын исәпкә алып;

2) йомшак -аерым территорияләрне төзекләндергәндә аларның үзенчәлекләрен исәпкә алып (шул исәптән балалар, спорт мәйданчыклары, этләрне йөртү өчен мәйданчыклар, җәяүлеләр йөрү юллары);

3) экологик яктан аеруча отышлы газон капламы.

Каты төрләренең өслеге тайгак булмаска тиеш (коры вакытта эләктерү үзлеге 0.6, юештә-0,4 коэффициентлы).

**Өслекләр тоташу**

151. Пандуслар, баскычлар, басмалар, борт ташлары өслекләр тоташуга керә.

**Борт ташлары**

152.Борт ташлары тротуар һәм машиналар йөрү өлеше кисешкән урында 150мм дан артык булмаган биеклектә урнаштырылырга һәм ремонт вакытында сакланырга тиеш.

Газоннарга транспорт чараларын кертмәү максатында, ул урыннарда борт ташларын биегрәк итеп урнаштыру рөхсәт ителә.

Газон белән җәяүлеләр юлы кисешкән урыннарда, газоннарны пычрактан һәм чүптән саклау максатыннан, 0.5 м арада 50мм чыгып торучы бакча бортлары ясарга мөмкин.

Җәяүлеләр зоналары территориясендә төрле өслекләрне тоташтыру өчен табигый материаллардан (кирпеч, агач, керамика) файдаланырга мөмкин.

**Баскычлар, басмалар, пандуслар**

153. Җәяүлеләр юлы 60 промиллдан артык авышлыкта булганда, баскычлар урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм башка объектлар урнашкан урыннарда җәяүлеләр юлларында, инвалидлар һәм картлар йортларында авышлык 50 промиллдан артык булганда баскычлар һәм пандус ясарга кирәк.

Бордюр пандусының авышлыгы 1: 12 кабул ителә.

Төшү һәм менү өчен баскычларның беренче басмаларын ачык контраст буяулар белән аерып буярга кирәк.

Тышкы баскычларның барлык басмалары бер марш чикләрендә баскычларның киңлеге һәм биеклеге буенча бертөрле билгеләнә.

Гражданнар өчен пандус конструкцияләре булмаса, 75 мм биеклектәге киртәле бортик һәм тоткычлар ясарга кирәк.

Пандусның башында һәм ахырында горизонталь юл өлешләре тирә-юньдәге өслекләрдән текстура һәм төс белән аерылып тора.

Баскычлар яки пандусларның ике ягы буйлап кул белән тотыну өчен 800-920 мм биеклектә, стенадан 40 мм ераклыкта, түгәрәк яки турыпочмаклы рәвештә тоткыч ясала.

**Мәйданчыклар**

154. Җирлек территориясендә түбәндәге мәйданчыклар була: балалар уеннары, өлкәннәр өчен ял итү, спорт белән шөгыльләнү, чүп җыйгычлар урнаштыру, этләрне урамда йөртү һәм өйрәтү, автомобиль стоянкалары.

Теркәлгән мәдәни мирас һәйкәлләре һәм махсус саклanучан табигать территорияләре зоналары чикләрендә мәйданчыклар урнаштыру һәйкәлләрне саклау, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтле органнар белән килештерелеп башкарыла.

Йорт яны территорияләре, кагыйдә буларак, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары белән тәэмин ителергә тиеш. Мәйданчыклар төзек һәм имгәнү куркынычы булмаган инвентарь белән тәэмин ителергә тиеш.

**Балалар мәйданчыклары**

155. Балалар мәйданчыклары төрле яшь төркемнәре өчен аерым мәйданчыклар яки яшь мәнфәгатьләренә кагылышлы комплекслы уен мәйданчыклары буларак оештырыла.

Балалар мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: йомшак өслек төрләре, газонлы мәйданчык өслеген тоташтыру элементлары, яшелләндерү, уен җиһазлары, эскәмияләр һәм урналар, яктырту җиһазлары.

Торак йортлар һәм иҗтимагый биналар тәрәзәләреннән мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәйданчыклары чикләренә кадәр ара 10 метрдан да ким булмаска тиеш, кече һәм урта мәктәп яшендәгеләр өчен - 20 метрдан да ким булмаска тиеш, комплекслы уен мәйданчыклары - 40 метрдан да ким түгел, спорт-уен комплекслары - 100 метрдан да ким булмаска тиеш.

Балалар өчен уен мәйданчыклары контейнер мәйданчыкларыннан 20 метрдан да ким урнашмаска тиеш.

156. Балалар мәйданчыкларында түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) җәй көне тигезләү өчен җиргә ком салынырга тиеш;

2) иртәнге якта себерелергә һәм юешләтелергә тиеш;

3) мәйданчыкта коймалар һәм корылмаларны буяу елга бер тапкырдан да ким түгел, ә ремонт эшләре кирәк булганда башкарылырга тиеш;

4) балалар мәйданчыгы җәяүлеләр хәрәкәтеннән, юллардан, борылу мәйданчыкларыннан, кунак машиналар кую стоянкаларыннан, калдыклар өчен

контейнерлар урнаштыру мәйданчыкларыннан, автотранспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау участокларыннан аерымланган булырга тиеш.

Имгәнүләр булмасын өчен мәйдан территориясендә чыгып торган тамырлары булган яисә аскы ботаклары салынган агачлар, җир өстенә чыгып торган киселгән җиһазлар (стойкалар, фундаментлар) булу рөхсәт ителми.

Якын-тирә территорияләрне реконструкцияләгәндә балалар мәйданчыклары территориясенә төзелеш материаллары ташу һәм урнаштыру рөхсәт ителми.

Яктырту җиһазлары, кагыйдә буларак, мәйданчык урнашкан территорияне яктырту режимында эшләргә тиеш.

Яктырту җиһазларын 2,5 метрдан да түбәнрәк урнаштыру рөхсәт ителми.

Уен җиһазларын урнаштыру куркынычсызлык нормативларын исәпкә алып башкарылырга тиеш.

157.Балалар мәйданчыкларын карап тоту һәм аларда иминлекне тәэмин итү өчен җаваплылык аларны карап тотуны гамәлгә ашыручы затларга йөкләнә.

**Спорт мәйданчыклары**

158. Спорт мәйданчыклары халыкның барлык яшь төркемнәре өчен дә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен билгеләнә.

Спорт мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге йомшак яки газон өслеге (җәйге чорда), спорт җиһазларын үз эченә ала.

Спорт мәйданчыклары яшелләндерелә һәм койма белән әйләндереп алына. Яшелләндерү мәйданчык периметры буенча башкарыла, вертикаль яшелләндерү кулланырга мөмкин. Койманың биеклеге 2,5-3 м тәшкил итә, бер-берсенә карата мәйданчыклар тоташкан урында-1,2 м дан да ким булмаска тиеш.

Спорт җиһазлары спорт, физкультура мәйданчыкларында яки рекреация составында махсус җиһазландырылган җәяүлеләр юлларында урнаштырыла. Махсус физкультура снарядлары һәм тренажерлар заводта эшләнгән яисә махсус эшкәртелгән өслекле бүрәнәдән һәм бруслардан эшләнгән булырга мөмкин (ярыклар, кимчелекләр булмау мөһим).

Урнаштыру вакытында сертификацияләнгән җиһазлар каталогларына таянып эш итәргә кирәк.

**Ял мәйданчыклары**

159. Торак төзелеше территориясендә өлкән буын кешеләрнә тыныч ял итү һәм өстәл уеннары өчен билгеләнгән ял мәйданчыклары оештыру мөмкин. Торак йортларның тәрәзәләреннән ял итү мәйданчыклары чикләренә кадәр ара 10 метрдан да ким булмаска тиеш, актив өстәл уеннары мәйданчыклары - 25 метрдан да ким булмаска тиеш.

Ял мәйданчыгында төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге: каты өслек төрләре, газонлы мәйданчык өслеген тоташтыру элементлары, яшелләндерү, ял итү өчен эскәмияләр һәм өстәлләр, урналар (ким дигәндә, һәр эскәмиядә берәр), яктырту җиһазлары.

Мәйданчыкны каплауны плитка түшәү рәвешендә проектларга тәкъдим ителә. Ял итү мәйданчыклары һәм балалар мәйданчыклары белән бергә балалар уеннары зонасында каты өслек урнаштырылуга юл куярга киңәш ителми.

Парк территорияләрендә ял итү өчен мәйданчыкларын үләндә оештырырга мөмкин.

**Этләрне йөртү һәм өйрәтү өчен мәйданчыклар**

160. Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар вәкаләтле органнар белән билгеләнгән тәртиптә килешенгән урыннарда урнаштырыла.

Этләрне урамда йөртү мәйданчыгы территориясендә төзекләндерү элементлары исемлеге: төрле өслек төрләре, коймалар, эскәмияләр, урналар, экскрементларны утильләштерү өчен контейнер, яктырту һәм мәгълүмати җиһазлар. Периметрны яшелләндерергә мөмкин.

Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар микрорайонның гомуми файдалану территорияләрендә яшел зоналардан читтә буш урыннарда, метрополитен линияләренең техник зоналарында һәм гомумҗирлек магистральләрендә, беренче һәм икенче поясларны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар зонасыннан читтә 110 кВт көчәнешле электр тапшыру линияләре астында урнашырга мөмкин.

Торак билгеләнешендәге территорияләрдә урнашкан мәйданчыклар күләме 400-600 кв. м чикләрендә кабул ителә, башка территорияләрдә - 800 кв.м. га кадәр, төзелеш барган очраклард, булган территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, мәйданчыкларның киметелгән күләме кабул ителергә мөмкин.

Мәйдан чигеннән торак һәм җәмәгать биналары тәрәзәләренә кадәр ара 25 метрдан да ким булмаска тиеш, ә балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыклары участокларына кадәр 40 метрдан да ким булмаска тиеш.

Мәйданчык коймасы, кагыйдә буларак, 1,5 метрдан да ким булмаган җиңел металл челтәрдән эшләнә.

Мәйданчык территориясендә мәйданчыкны файдалану кагыйдәләре буенча мәгълүмати стенд урнаштырылган булырга тиеш.

161. Йорт хайваннары хуҗалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль рәвештә җыюны һәм утильләштерүне башкаралар.

Йорт хуҗалары хайваннарының башка хайваннарга һәм кешеләргә куркыныч йогынтысын булдырмый калырга, шулай ук тирә-юньдәгеләр өчен санитар

нормалар нигезендә тынычлыкны тәэмин итәргә, гамәлдәге санитар-гигиена һәм ветеринария кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

**Автостоянка мәйданчыклары**

162. Җирлек территориясендә түбәндәге төр автостоянкалар урнаш а ала: автомобильләрне кыска вакытлы һәм озаклап саклау.

Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакыт эчендә саклау участогында урыннары өслек төрләре, коймалар, чүп-чар өчен урналар яки контейнерлар, яктырту җиһазлары, мәгълүмат җиһазлары (күрсәткечләр).

Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннарына керү юллары җәяүлеләр юлларының төп юнәлешләре белән кисешергә тиеш түгел.

Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау участогы аша транзит җәяүлеләр юлларын оештыру рөхсәт ителми.

Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау участогы калган территориядән 3 метрдан да ким булмаган яшел утыртмалар полосасыннан изоляцияләнергә тиеш.

**Кече архитектура формалары**

163. Кече архитектура формаларын урнаштыру төзелеш, биналарны һәм корылмаларны реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проект документлары, шулай ук төзекләндерү яки эскиз тәкъдимнәре проектлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кече архитектура формаларын проектлаганда һәм сайлаганда сертификацияләнгән эшләнмәләр каталогларыннан файдаланырга киңәш ителә. Җирлекнең үзәге, бистәдәге күп функцияле үзәкләр һәм кече архитектура формалары зоналары өчен шәхси проект эшләнмәләре нигезендә проектланырга тиеш.

164. Кече архитектура формаларына карата төп таләпләр:

1) архитектура һәм ландшафт тирәлеге характерына, территорияне төзекләндерү элементларына туры килү;

2) материалларның югары декоратив һәм куланылыш сыйфатлары, тышкы мохит йогынтысын исәпкә алып, озак вакыт дәвамында аларны саклый алу;

3) конструкциянең ныклыгы, ышанычлылыгы, иминлеге.

**Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары**

165. Тышкы реклама һәм мәгълүмат  чараларын урнаштыру

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан матур булырга тиеш.

Тышкы мәгълүмат чаралары, оешма турында элмә такталардан һәм режим турында  табличкалардан тыш, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорт нигезендә урнаштырыла;

 Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары хуҗалары аларның торышын күзәтеп торырга, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын вакытында ремонтларга һәм җыештырырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны аларга реклама яки мәгълүмати хәбәр урнаштырмыйча урнаштыру һәм эксплуатацияләү, мәгълүмат кырына зыян китерү, шулай ук тышкы реклама чараларын һәм мәгълүматны полиэтилен пленка һәм башка материаллар белән каплау рөхсәт ителми.

Реклама яки мәгълүмати конструкция хуҗасы территорияне төзекләндерүне һәм (яки) фасадның тышкы кыяфәтен монтажлауны (сүтүне ) өч тәүлек эчендә башкарырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары, аларның фундаменты блогы булганда, аның  белән бергә сүтелергә тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштырганда корылмаларга зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын һәм тотрыклылыгын бетерү рөхсәт ителми.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары түбәндәге төрләрдә  булырга мөмкин:

1)стена конструкциясе;

2) декоратив панно;

3) консоль конструкциясе;

4) түбә конструкциясе;

5) витрина конструкциясе;

6) оешма элмә тактасы;

7) режим турында табличка;

8) модульле конструкция;

9) стела;

10)щитлы конструкция;

11) күләмле-киңлек композициясе;

12) флаг композициясе;

13)махсус конструкция.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларына гомуми таләпләр:

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларын проектлау, әзерләү һәм урнаштыру Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Россия Федерациясе законнары таләпләренә, аларны саклау һәм куллану таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш;

Тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт теле турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш;

Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча дөрес булырга тиеш.

166. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру рөхсәт ителми:

1.күпфатирлы торак йортларның фасадларында:

1) торак урыннар чикләрендә, беренче һәм икенче катлар арасында урнашкан конструкцияләрдән, турыдан-туры биләп торган торак булмаган бина өстендә урнашкан конструкцияләрдән; торак йорт габаритларында урнашкан, аның чикләрендә 1,5 м дан да артык булмаган һәм мәгълүмати конструкцияне урнаштыручы зат биләгән торак булмаган бинадан, беренче һәм икенче катлар арасында урнашкан конструкцияләрдән, торак булмаган бинадан тыш;

2) тәрәзә һәм ишек  уемнарында, шулай ук витриналарны, әлеге Кагыйдәләрдә каралган очраклардан тыш, тулы яисә өлешчә ябу рәвешендә; лоджия, балконнар, койма конструкцияләрендә; керү төркеменең проект тәкъдиме белән каралган очраклардан тыш, бер конструкциядән артык;  бер керү урыны булган очракта, бер конструкциядән артык;

2. торак булмаган бина фасадларында:

1) биш каттан артык биеклектәге биналарда вертикаль консоль конструкцияләрдә;

2) әлеге Кагыйдәләрдә каралган очраклардан тыш, икенче кат тәрәзәләренең аскы өлешеннән югарырак;

3. фризларда, керү төркемнәренең козырекларында:

1) бер ишек булганда -бер конструкциядән артык;

2) ут тартмаларында, фон конструкцияләре рәвешендә, керү урыны булган керү төркеме фризында урнаштырылганнан тыш;

4. төзелү датасы 1959 елга кадәрге мәдәни мирас объектларында, тарихи биналарда:

1) җемелдәвек ут кулланып, фон конструкцияләрендә, ут тартмалары, динамик конструкцияләрдә, витрина һәм консоль конструкцияләрендә,  декоратив паннолардан тыш;

2) контраст һәм ачык төс схемасында архитектура фонына туры килми торган;

3) мондый объект проектында каралмаган, гомуми мәйданы 400 кв. метрдан артык булган административ офис, сәүдә, мәдәни-күңел ачу, спорт объектларында;

4) аерым торучы конструкцияләр рәвешендә шәхси яки күпфатирлы торак йортлар территорияләрендә;

5) әлеге Кагыйдәләрдә каралган очраклардан тыш, биналарда уемнарны, витрина, тәрәзәләр, тәрәзә пыяласы, архитектура детальләре һәм декоратив-сәнгать бизәлешен каплаган;

6) эркерларда, колонналарда, пилястрларда, балконнарда;

7) мемориаль такталардан 2,0 м ераклыкта;

8)адреслы атрибутиканы каплаган (урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләре);

9) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" Федераль законның 9 статьясы нигезендә мәҗбүри булмаган мәгълүмат (оешманың фирма атамасы (атамасы), аның урнашу урыны (адресы) һәм аның эш режимы турында мәгълүмат), аерым алганда, модульле конструкцияләр, шулай ук щитлы һәм витрина конструкцияләреннән тыш, биналарны арендалау, сату турындагы мәгълүматның юнәлешләрен, исемлеген билгели торган;

10) текстлы мәгълүматтан башка гына сурәтләрне үз эченә алган; 13) төс буенча фасадның архитектура фоны белән ярашмаган; 14) ачык яктырту ысулы кулланылган.

**Гражданнар игъланнарын, мәдәни һәм спорт чаралары афишаларын урнаштыру**

167. Мәдәни һәм спорт чаралары афишаларын гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм җәяүлеләр күпләп йөри торган урыннарда урнаштырыла торган махсус тумбаларда, щитларда һәм стендларда гына урнаштыру рөхсәт ителә.

Игъланнар өчен стендлар аерым торучы объектлар рәвешендә яки биналарда яки корылмаларда асылмалы щитлар рәвешендә урнаштырыла ала.

**Коммуникацияләр төзегәндә, ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә җир эшләре башкаруга төп таләпләр**

168. Грунт казу яки юл катламнарын ачу (җир асты коммуникацияләрен сузу, реконструкцияләү яки ремонтлау, свай һәм шпунтка утырту, электр тапшыру линияләрен, элемтә баганаларын урнаштыру (алмаштыру), яктырту баганалары, грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында һәм башка эшләр) белән бәйле эшләр вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән язма рөхсәт (җир эшләрен башкаруга ордер) булганда гына башкарыла.

169. Җирлек территориясен төзекләндерү белән бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү тәртибе, җир эшләрен башкаруга ордер ясау һәм алу муниципаль хокукый актларның билгеләнгән таләпләре нигезендә башкарыла.

170. Яшел зоналарны бетерергә яки күчереп утыртырга туры килгәндә, ул эшләрне Башкарма комитет карары нигезендә башкарырга кирәк.

171. Җирлек юллары буенча хәрәкәтне вакытлыча чикләү яки туктату вәкаләтле орган тарафыннан юлның ике ягында заказчылар һәм эш башкаручылар, эшләр сроклары, карап чыгу мөмкин булган маршрутлар турында кирәкле барлык мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат щитын урнаштыру юлы белән мәҗбүри рәвештә бирелгән рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән щитның рәвеше һәм эчтәлеге рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең тиешле административ регламенты белән билгеләнә.

172. Яраклылык вакыты чыккан ордерлар буенча башкарылганда, җир эшләрен башкару үзбелдекле дип таныла.

**Уңайлы мохиткә аерым таләпләр**

173. Урамнарны һәм юлларны, мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын проектлаганда, өлкән яшьтәге кешеләр һәм инвалидлар өчен уңайлы мохит булдыру мөмкинлеген, әлеге объектларны картлар һәм инвалидлар хәрәкәт итә алырлык элементлар һәм техник чаралар белән тәэмин итүне күздә тотарга тәкъдим ителә.

Өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар йөри торган техник чаралар һәм җиһазларны проектлау, төзү, урнаштыру заказчы тарафыннан расланган проект документациясе нигезендә яңа төзелеш вакытында тормышка ашырырга тәкъдим ителә.

**Биналар һәм корылмалар (аларда бүлмәләр) милекчеләренең якын-тирә территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибе**

174. Җирлек территорияләренең тиешле санитар торышын тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне пычратудан саклау һәм яклау чараларын тормышка ашыру максатыннан, җирлек территориясен чистарту һәм санитар тәртиптә тоту өчен хуҗалык итүче субъектларга һәм физик затларга беркетелә.

175. Территорияләрне (җир кишәрлекләрен) җыештыру, чистарту һәм санитар тоту буенча эшләр башкару бурычлары, әгәр законда яки килешүдә башкасы каралмаган булса, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, физик һәм юридик затларга йөкләнә:

1)идарәче оешмалар -күпфатирлы йортларның йорт яны территориясе, шулай ук күпфатирлы йорт территориясе каршындагы төп фасад ягыннан 5 м радиуста яисә урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

2) социаль өлкә учреждениеләре (мәктәпләр, мәктәпкәчә учреждениеләр, мәдәният, сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт учреждениеләре) - бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә территория, шулай ук учреждениенең территориясе алдында 10 м радиуста төп фасад ягыннан яисә урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта), башка яктан-10 м радиуста;

3) күпфатирлы торак йортларда торак булмаган биналарны эксплуатацияләүче затлар- идарәче оешма белән килешү булмаганда, якындагы территорияне биналарның бөтен озынлыгына, киңлеге - 10 м яки йөрү өлеше бордюрына кадәр (юл буенда объект урнашкан очракта) җыештырырга хокуклы;

4) барлык милек рәвешләрендәге сәнәгать предприятиеләре һәм оешмалары - аларга килү юллары, тротуарлар, алар янәшәсендәге коймалар, санитар-яклау зоналары. Предприятиеләрнең санитар-сак зоналары гамәлдәге санитар кагыйдәләр һәм нормалар таләпләренә туры китереп билгеләнә;

5) төзүче-50 м радиуста төзелеш мәйданчыкларының якын-тирә территорияләре һәм гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә 50 м радиуста аларга килү юллары;

6) бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә торак йортларның хуҗалары - җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, фактта барлыкка килгән җир кишәрлегенең чиге буенча һәм йорт алдындагы территория 5 м ераклыкта яисә урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

7) стационар булмаган объектлар (лотоклар, киосклар, павильоннар һәм башка стационар булмаган сәүдә объектлары) һәм сезонлы кафелар - урнашу өчен бирелгән җир кишәрлеге объекты территориясе һәм аның тышкы чигеннән 10 м ераклыкта һәм урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

8) базарларның идарәче компанияләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары (ресторааннар, кафе, кибетләр) - бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территорияләр һәм участок чикләреннән 50 м радиуста урнашкан территория һәм урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

9) биналарның, корылмаларның милекчеләре яки башка хокук ияләре-бина, корылма периметры буенча яисә бирелгән җир кишәрлегенең чикләре һәм кишәрлек чигеннән 10 м радиуста булган территория һәм урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

10) автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә һәм башка җир кишәрлекләрендә урнашкан заправка станцияләре - бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә һәм кишәрлек чигеннән 50 м радиуста урнашкан территория һәм урамның йөрү өлешенә кадәр;

11) гараж кооперативлары - бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территорияләр, 50 м радиуста урнашкан территория, участок чигеннән алып урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр һәм аларга керү юллары;

12) бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә җирләү урыннары һәм кишәрлек чикләреннән 10 м радиуста якындагы территория;

13) гомуми файдаланудагы территорияләр һәм вазыйфалар вәкаләтле органга йөкләнә;

14) бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә җир кишәрлекләренә ия булучылар- (яки җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, фактта барлыкка килгән чиге буенча) һәм җир кишәрлегенең тышкы чигеннән 5 м ераклыкта яки урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

15) автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау өчен тукталышларның хуҗалары- бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә территория һәм җир кишәрлегенең тышкы чигеннән 10 м ераклыкта һәм урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта).

Якын-тирә территорияләрнең чикләрен билгеләү яки үзгәртү, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнә торган форматлар нигезендә, җирлек Советы тарафыннан тирә-юнь территорияләре чикләренең схемасын раслау юлы белән гамәлгә ашырыла.

**Йорт хайваннарын һәм кошларын асрау**

176. Йорт хайваннарын һәм кош-кортларны карап тоту өченче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш, йорт хайваннарына һәм кошларына китерелгән зыян өчен җаваплылык гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларның хуҗаларына йөкләнә.

177. Йорт хайваннары хуҗалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль рәвештә җыюны һәм утильләштерүне башкаралар.

178. авыл хуҗалыгы терлекләрен (сыер, сарык, кәҗә, дуңгызлар һәм башка) һәм кошларны тоту авыл җирлегендә яшәүчеләргә йорт яны участоклары белән шәхси йорт территориясендә рөхсәт ителә.

179. Барлы кпродукция бирүче хайваннар (мөгезле эре терлек, кәҗәләр, сарыклар, дуңгызлар, атлар), гражданнарның яшәү урыны буенча ветеринария учреждениеләрендә ел саен яңадан теркәлергә тиеш.

180. Йорт хайваннарын җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган көтү урыннарында хуҗасы күзәтүе астында яки аның кушуы буенча башка затның күзәтүе астында рөхсәт ителә.

181. Йорт хайваннарын 7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр урамда йөртү рөхсәт ителә. Башка вакытта урамда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү өчен хуҗалар чаралар күрергә тиеш.

182. Этләрне урамда йөртү, өч айга кадәрге эт балаларын һәм кечкенә этләрне йөртү очракларыннан тыш, чылбыр (этне тотып торучы бүтән җайланма), муенчак һәм борынчак кулланып башкарылырга тиеш (әгәр алар махсус сумкада (контейнерда) яки аларны урамда йөртүче зат кулында булмаса). "Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында" 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән эт муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә тиеш. Этләрне сәбәпсез урамда йөртү торак пунктлардан читтә, шулай ук урамда йөрергә рөхсәт итүче билгеләр куелган урыннарда рөхсәт ителә.

183. Хуҗалары йорт хайваннары һәм кошлары тарафыннан тротуарларның, урамнарның, паркларның, газоннарның, балалар мәйданчыклары, скверларның, мәйданнарның, шулай ук торак йортларның подъездларының пычрануына юл куймаска тиеш. Эт, мәчеләр һәм башка вак хайваннарны урамда йөрткәндә, хуҗасы табигый яшәеш калдыкларын тулысынча җыюны тәэмин итә торган кирәк-яраклар булдырырга һәм аны үз вакытында контейнерларга ташларга тиеш.

184. Этне махсус урыннарда гына ычкындырырга була. Махсус билгеләнгән мәйданчыклар булмаганда, җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган буш урыннарда йөртү рөхсәт ителә.

185. Этләрне өйрәтү бары тик яхшы итеп әйләндереп алынган мәйданнарда яки җирлек территориясендә генә алып барыла ала.

186. Йорт хайваннарын юл буйлап бары тик тәүлекнең якты вакытында гына һәм юлның уң ягына якынрак итеп куып алып барырга мөмкин. Йорт хайваннарын асфальт түшәлгән юл буенча грунт юллары һәм сукмаклар булмаганда гына йөртергә мөмкин.

187. Урамнарда йорт терлекләрен караучысыз калдырганда, хуҗалары яшел үсентеләрне бозудан килгән зыянны каплый.

188. Йорт кәҗәләре йорт яны территориясенең эчендә генә яки көтүлекләрдә хуҗалары күзәтүе астында гына асралырга тиеш.

189. Рөхсәт ителми:

1)малларны балалар һәм спорт мәйданчыкларында, пляжларда, мәгариф һәм медицина оешмалары территорияләрендә йөртү;

2) йорт хайваннарын гражданнарның күпләп ял итү урыннарында урнашкан пляжларда йөртү һәм аларны сулыкларда коендыру;

3) тыючы язулар булганда, хайваннарны учреждениеләргә кертү;

4)торак пунктлар территориясендә хайваннар һәм кошларны караучысыз калдыру;

5) хайваннар йөрүне контрольдә тота алмаган һәм урамда йөргәндә агрессив тәртибен чикли алмаган затлар, шулай ук яше яки сәламәтлеге аркасында

хайваннар йөрүне контрольдә тота алмаган затлар хайваннарны урамда йөртергә тиеш түгел; 14 яшькә җитмәгән затлар тарафыннан этләрне урамда йөртү (кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш);

6) балкон, лоджияләрдә, торак йортларның гомуми файдалану урыннарында (чиктәш фатирлар коридорлары, баскыч, чорма, подвал һәм башка ярдәмче биналарда) йорт хайваннарын һәм кошларын даими асрау;

7) йорт хайваннарының махсус билгеләнгән урыннадан тыш җирләрдә булуы (чаралар (күргәзмәләр һ.б.) үткәрү урыннарыннан тыш ).

190. Йорт хайваннары һәм кошлары хуҗаларының бурычлары:

1)хайван авыруларын кисәтү, терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария таләпләренә җавап бирүен тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймау, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын үткәрү;

2) хайваннарның асралу урынын даими контрольдә тоту;

3) хайваннар чирләгәндә һәм үлгән очракта, шулай ук үзләрен сәер тотканда, кичекмәстән ветеринария учреждениеләре белгечләренә хәбәр итәргә кирәк. Алар килеп җиткәнче авыру хайваннарны башкаларыннан аерып ябарга кирәк.

4) ветеринария белгечләре таләбе буенча диагностика тикшеренүләре, саклану прививкалары һәм дәвалау-профилактика эшләре өчен хайваннарны бирергә кирәк.

191. Үлгән хайваннарны күмү махсус билгеләнгән урында махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарыла.

192. Үз территорияләрендә каравылчы этләре булган оешмалар бурычлы:

1) этне гомуми нигезләрдә теркәргә;

2) эт ныклы бәйдә асрарга;

3) килүчеләрнең хайваннар янына керү мөмкинлеген булдырмаска;

4) этләрне бәйдән бары тик яхшы әйләндерелгән территориягә яки гомуми файдаланудагы территориядән янган территориягә кергәндә кисәтү язуы булган очракта гына җибәрергә кирәк

193. Җәмәгать урыннарындагы озатып йөрүче затлары булмаган күзәтүчесез хайваннар ауланырга тиеш.

194. Күзәтүчесез хайваннарны аулау махсус предприятие яки җирле үзидарә органнары белән төзелгән килешү нигезендә башкарыла ала.

195. Күзәтүчесез хайваннарны аулау чараларын гамәлгә ашыру хайваннарга карата гуманлы мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларына нигезләнә.

196. Рөхсәт ителми:

1) тиешле карардан башка, шәхси йортлар территориясеннән һәм фатирлардан хайваннарны тартып алырга;

2) этләрне кибет, даруханәләр, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре һ. б. янында бәйдән ычкындырырга;

3) ветеринария органнары рекомендациясеннән башка, алдавычлар һәм башка аулау чаралары кулланырга.

**Кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту**

197. Физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар җирлек территориясен төзекләндерү буенча әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

198. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә (федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган нормаларны һәм кагыйдәләрне үз эченә алган, аларны үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә җаваплылык билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) җаваплылыкка тартыла.

199. Төзекләндерү өлкәсендәге закон таләпләрен һәм муниципаль хокукый актларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкка тарту әлеге таләпләрне үтәүдән һәм ясалган җитешсезлекләрне бетерүдән азат итми.

Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге Советының
28.10.2021 №29
карарына 2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советының «Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектына тәкъдимнәр, авторның яшәү урыны турында белешмә, Ф.и. а.и. күрсәтелеп, 2021 елның 15 ноябренә кадәр язмача кертелә. Тәкъдимнәр ТР, Арча районы,Үрнәк авылы, Урман урамы,44А йорт адресы буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советына җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырылганнан соң, дүшәмбе-җомга 8.00 -16.00 сәгатькә кадәр эшче төркем секретарена тапшырыла. Белешмәләр өчен телефон: 88436651493.

Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге Советының
28 .10 2021 №29
карарына 3 нче кушымта

**Арча муниципаль районы Үрнәкавыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча Арча муниципаль районы авыл җирлеге Советына шәхсән яки почта аша (конвертта «Төзекләндерү кагыйдәләрен тикшерү» дигән тамга белән) тапшырыла: ТР, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман урамы,44А йорт.
2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукына ия гавами тыңлауларда катнашучылар булып Арча муниципаль районы Үрнәкавыл җирлеге Советына язмача гаризалар биргән җирлек халкы тора.
3. Җирлекнең барлык кызыксынган халкы гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукыннан башка гына катнаша ала.
4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.
5. Чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.
6.Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артмаска тиеш.
7. Гавами тыңлауларда катнашучылар, рәислек итүче ризалыгы белән, чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә мөмкин.
8. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына комачауларга, аларны өзәргә хокуклы түгел.
9. Гавами тыңлаулар уздыру тәртибе гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырышлар залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.